• ӘДӘП ВӘ ӘХЛАК •
МӨСЕЛМАН – ИСЛАМНЫҢ КӨЗГЕСЕ
*4 бит*

• САБЫЙГА •
КОРЪӘН ЯХШЫНЫ ЯМАННАН АЕРЫРГА ӨЙРӘТӘ
*9 бит*

• НӘСЫЙХӘТ •
АДӘМ БАЛАСЫНЫҢ БИШ СЫЙФАТЫ
*12 бит*

• ӘДӘБИ СӘХИФӘ •
КҮРКӘМ ХОЛЫК НӘТИҖӘСЕ
*14 бит*

№ 10 (315) | Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы | сафәр-рабигыль-әүвәл, 1443

октябрь, 2021

# دين و معيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ



*Инсан акыллы, камил зат итеп яратылган. Аллаһы безгә биргән иман нигъмәте өчен Раббыбызны искә алу, мактау, Аллаһыга шөкер итү – инсанның бурычы. Безне даими исенә төшереп торучы һәм һич кенә дә онытмаучы Аллаһыны искә алып зикер итү – кешеләрнең иң мөһим вазифаларының берсе...*

*Дәвамы 6 нчы биттә*

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# Нәзарәт “Оста вәгазьче” бәйгесен игълан итте



***Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте «Оста вәгазьче» төбәкара дини бәйгесен игълан итте. Иҗади ярыш татар-мөселман яшьләрен һәм җәмгыятен рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләргә, катнашучыларның татар телендә чыгыш ясау һәм сөйләм күнекмәләрен камилләштерергә ярдәм итәчәк, ораторлык осталыгына ия талантлы татар шәхесләрен ачыкларга мөмкинлек бирәчәк. Бәйге Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында һәм Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан оештырыла.***

Бәйгедә үз көчләрен 18 яшьтән алып 45 яшькә кадәрге ир-атлар һәм хатын-кызлар сынный алачак. Конкурсның төп шарты буенча алар имам, хәзрәт һәм мәчет-мәдрәсәдә мөгаллим булып эшләүче булырга тиеш түгел.

Конкурс 3 этапта үткәрелә. Башта катнашучылар бирелгән темалар буенча татар телендә вәгазьләр язып, аларның текстларын электрон рәвештә marat-salakhov@yandex.ru почтасына җибәрергә тиеш булачак. Икенче этапта оештыручыларның критерийлары нигезендә иң яхшы эшләр сайлап алыначак. Өченче этапта жюри катнашында конкурсны ачык рәвештә, катнашучыларның үз вәгазьләре белән чыгышларын бәяләү көтелә. Бәйгедә вәгазь белән катнашу өчен 5 тема бирелә:

Тема 1: «Заманча технологияләр: безгә файдамы, зыянмы?»

Тема 2: «Туган тел – Аллаһыдан әманәт».

Тема 3: «Әйләнә-тирә мохитне саклау – фарыз гамәл».

Тема 4: «Заман һәм мөселман гаиләсе».

Тема 5: «Куллану җәмгыятенең» («Общество потребления») көнбатыш моделенә Исламча караш».

Текстның күләме 2-3 басма битне тәшкил итәргә тиеш (Times New Roman шрифты; шрифт зурлыгы – 14, юллар арасындагы интервал – 1,5; чикләр (поля): сулдан – 3 см, уңнан – 1 см, өстән – 2 см, астан – 2 см).

Эшләр 2021 елның 10 декабренә кадәр кабул ителә. Өченче этапка узган катнашучыларны билгеләү вакыты – 2021 елның 13 декабренә кадәр. Ачык бәйге Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте резиденциясендә (Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт) узачак һәм катнашучылар үзләре язган вәгазьләр белән чыгыш ясаячак. Чыгыш өчен бирелә торган вакыт – 5-7 минут. Конкурс таләпләре буенча, язма эшләрдә, ким дигәндә, сүрә исемен күрсәтеп бер Коръән аяте һәм, чыганагы күрсәтелеп, бер хәдис булырга тиеш. Конкурсантлар теманы ачуга, яңалыкка һәм идеяләрнең үзенчәлегенә (оригинальлегенә), телдән һәм язма сөйләмнең дөреслегенә, сөйләмнең темпына һәм аһәңенә (интонациясенә), аудиторияне тоемлавына карап бәяләнәчәк.

Бәяләүнең төп критерийлары – тәкъдим ителгән темага, сайланган стильгә һәм жанрга туры килү, теманы чикләнгән вакыт эчендә ача белү, сөйләмнең һәм телнең байлыгы, матурлыгы һәм дөреслеге, сөйләм темпы һәм интонациясе (сөйләм тизлеге, логик акцентлар, тонның күтәрелүе һәм түбәнәюе, пауза), аудитория белән эшләү һ.б.

Призлы урыннарны алган җиңүчеләр кыйммәтле бүләкләр һәм катнашучы дипломы белән бүләкләнәчәк.

Бәйгене оештыру мәсьәләләре буенча элемтәгә керү өчен телефоннар: +79270333142 (Айгөл ханым), +79272401302 (Марат).

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Татарстан мөселман уку йортлары мөгаллимнәре форумы узды



***12-13 нче октябрь көннәрендә Казанда Идел мөселман белем бирү оешмалары мөгаллимнәренең еллык форумы узды.***

Быел форум Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы һәм «Традицион диннәр теологиясе һәм мәгариф даирәсендә фәнни-педагогик һәм дини берләшмәләр хезмәттәшлеге» II Бөтенрәсәй симпозиумы кысаларында узды. Форум 2011 елдан башлап ТР мөселманнары Диния нәзарәте, Ислам мәдәнияте, фән һәм мәгариф фонды һәм Рәсәй ислам институты белән берлектә үткәрелә, мөселман мәгарифе һәм тәрбиясе өлкәсендәге мөһим мәсьәләләр турында фикер алышу һәм аларны хәл итү өчен мәйданчык булып тора. Форум, коронавирус инфекциясе таралуны кисәтү чараларын күреп, социаль аралыкны саклап оештырылды.

Форум кысаларында мөселман уку йортлары мөгаллимнәре Татарстан Республикасында дини белем бирү үзенчәлекләре белән бәйле мәсьәләләрне карады. “Ярдәм” милли ислам хәйрия фонды каршындагы Бөрбаш балалар пансионаты директоры Альберт Базагутинов “Балтач районы Бөрбаш авылында ир балалар өчен ислам пансионаты эшчәнлеге” темасына чыгыш ясады. Шулай ук Чаллы шәһәренең “Зиннәт” гаилә ял үзәген нигезләүче Ләйсән Әхмәтшинаның кече яшьтәге балаларның дини үсеше өлкәсендәге уңышлы эш тәҗрибәсе белән уртаклашты. Болгар ислам академиясе ректоры Айнур Тимерханов “БИАда магистрлар һәм докторлар әзерләү өчен мөмкинлекләр” хакында сөйләде. Моннан тыш, “Хозур” нәшрият йортының нәшрият бүлеге баш мөхәррире Ленар Хамматов 2021 елның башында үз эшен башлап җибәргән беренче татар онлайн-мәдрәсәсенең агымдагы нәтиҗәләре белән таныштырды.

Шулай ук, форум һәм Симпозиум эше барышында Татарстанның мөселман уку йортларының иң яхшы мөгаллимнәренә һәм студентларына, педагогик эшчәнлекләрендә һәм укуларында зур нәтиҗәләргә ирешкән шәкертләргә ТР мөселманнары Диния нәзарәте бүләкләре, шул исәптән ТР Мөфтиенең рәхмәт хатлары һәм исемле стипендияләре тапшырылды.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

**Фотолар dumrt.ru** сайтыннан алынды

# Казан шәкертләре “Хозур” интеллектуаль уеннарында көч сынашты



***Казанның “Мөхәммәдия” мәдрәсе, Коръән хафизлар әзерләү үзәге һәм Рәсәй ислам институты шәкертләре Мәүлид ае уңаеннан “Хозур” интеллектуаль уеннарында көч сынашты.***

Викторина “Нәрсә? Кайда? Кайчан?” форматында "Хозур" нәшрият йорты тарафыннан оештырылды. Командаларга бүленеп көч сынашучы егетләр-кызлар Пәйгамбәребезнең сирасы, фикһы, гакыйдә һәм Коръән фәннәре буенча сорауларга җавап бирде. Шәкертләрнең белемнәрен җюри буларак чакырылган остазлар бәяләде.

Мисал өчен, Рәсәй ислам институты мөгаллиме Әмир хәзрәт Садыйков билгеләп үткәнчә, «Хозур» уены укучыларга институтта алган белемнәрен ныгытырга һәм ислам диненең кайбер яңа аспектларын өйрәнергә мөмкинлек бирде. Гомумән алганда, викторинада катнашучылар ислам гакыйдәсен белү буенча яхшы нәтиҗәләр күрсәттеләр, сорауларга актив җавап бирделәр һәм әлеге чараны оештыручыларга рәхмәтләрен белдерделәр.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең “Хозур” нәшрият йорты исеменнән барлык җиңүчеләргә, шулай ук интеллектуаль уеннарда катнашучыларга китаплар тапшырылды.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Казанда Халыкара конференция үткәрелде




**14-15 нче октябрь көннәрендә Казанда «Хәзерге Рәсәйнең фәнмәгариф киңлегендә традицион диннәр теологиясе» исемле Халыкара фәнни-гамәли конференция үтте.**

Конференциянең пленар утырышын ТР мөфтие урынбасары, РИИ һәм КИУ ректоры, Ислам мәгарифе Советы рәисе Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин алып барды. Утырыш Коръән аятьләре уку белән башланды һәм катнашучылар адресына рәсми сәламләү сүзләрен җиткерү белән дәвам итте. Конференциянең тантаналы ачылышында сәламләү чыгышлары Фәнни-белем бирү теология ассоциациясе президенты (НОТА), ОЦАД ректоры митрополит Волоколамский Иларион, ТР мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Андрей Поминов һәм ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров исеменнән чыгышлар яңгырады. Мисал өчен, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәровның сәламләү мөрәҗәгатен яңгыратып, ТР Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе баш киңәшчесе Әскәр Гатин бүген Татарстанда дини һәм теологик белем бирүнең нәтиҗәле системасы төзелгән булуын билгеләп үтте һәм күптән түгел дөнья күргән «Гражданская идентичность мусульман России» дәреслегенең авторлык коллективына рәхмәтен белдерде, шул исәптән, дәреслекне әзерләүдә ТР мөфтие урынбасары, РИИ һәм КИУ ректоры Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин да үз өлешен кертте.

Аннары Татарстанның традицион конфессияләре лидерлары – Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Казан рухи семинариясе ректоры Владимир атакай, Татарстанның баш раввины Реб Ицхак Горелик сүз алды.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үз чыгышында конференциянең истәлекле вакыйга – Идел буе Болгар дәүләтендә исламны динен рәсми кабул итүгә 1100 ел тулу алдыннан узуын искә төшерде. «Бу истәлекле дата татар халкы һәм Рәсәй мөселманнары тарихында иң истәлекле даталарның берсе булып санала. Ул Исламны күпмилләтле Россиянең төп халыклары тоткан дин булуын дәлилли. Димәк, бүген Рәсәйдәге күпдинле җәмгыятьнең асылын исламнан башка танып булмый, чөнки бөек Рәсәй милләтен формалаштыруда мөселманнар да катнашты», – диде мөфти. Аннары ул җыенда катнашучыларның игътибарын илдәге ислам теологиясенең, иң беренче чиратта, үз дини мирасына һәм Рәсәй территориясендә 11 гасыр дәвамында яшәп килгән традицияләргә нигезләнергә тиешлеген әйтте: “Ата-бабаларыбыз безнең өчен бәяләп бетергесез рухи мая калдырган, һәм безнең бурычыбыз – аларны өйрәнү һәм үзләштерү, популярлаштыру һәм аларга карата яшьләрдә кызыксыну уяту». Мөфти Рәсәй мөселманнарының гражданлык һәм милли үзенчәлеге мәсьәләләренә тукталды, һәм Татарстан мөселман мәгариф учреждениеләрендә укучылар арасында гражданлык һәм милли үзаңны формалаштыруга аерым игътибар бирүен искәртте. – Рәсәйнең күпсанлы халыклар һәм дини төркемнәр өчен зур йорт булуы беркемдә дә шик булырга тиеш түгел. Илебезнең чикләрен яклауда, Рәсәй дәүләтчелеген төзүдә, аның икътисадын үстерүдә барча төпле халыклар катнашты. Рәсәй иминлеге халыклар арасындагы үзара аңлашуга нигезләнә. Моны дини генә түгел, дөньяви уку йортларында да аңлатырга кирәк”, – дип мөфти йомгак ясады.

Катнаш форматта уза торган конференциядә Рәсәй Федерациясе һәм Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләре, Рәсәйнең 40 ка якын «Теология» укыту юнәлешен тормышка ашыручы, шул исәптән, Ислам дини югары уку йортлары ректорлары һәм башка вәкилләре катнашты. Мисал өчен, экспертлар арасында БИА, Дагыстан, Чечня, Рәсәй мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте ислам институтлары вәкилләре, дөньяви югары уку йортлары ректорлары һәм вәкилләре, шул исәптән РФ Президенты каршындагы Рәсәй халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе, Пятигорск дәүләт университеты, Рәсәй дәүләт университеты, Мәскәү педагогика дәүләт университеты һ.б. кебек дөньяви югары уку йортлары ректорлары, проректорлары һәм вәкилләре бар иде. Моннан тыш, конференция эшенә Мөхәммәд бине Зәед исемендәге Гуманитар фәннәр университеты ректоры Халид Әл-Ябхүни (Әбү Даби шәһәре, БГӘ), Мисырның “Нур-Мөбарәк” ислам мәдәнияте университеты, Сиди Мөхәммәд бине Габдулла (Фәс шәһәре, Марокко) һәм Сәбәхәддин Заим исемендәге университет (Истанбул шәһәре, Төркия) мөгаллимнәре кушылды.

Конференция кысаларында төп эш юнәлешләре булып илнең рухи иминлеге, динара татулык, дәүләт һәм дин арасындагы бәйләнешләр, дин тотучыларның гражданлык үзенчәлекләре, мәдәни күптөрлелекне саклау, студент-теологның фәннитикшеренү фикерләү культурасын формалаштыру, фәнни-педагогик һәм дини берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеге, бердәм динара фәнни кыр булдыру өчен дөньяви һәм төрле диннәр белән бәйле рухи уку йортлары галимнәренең һәм мөгаллимнәренең тырышлыгын берләштерү мәсьәләләре торды.

**dumrt.ru** сайтыннан

**Фотолар dumrt.ru** сайтыннан алынды

# Мөселман – исламның көзгесе

***Исламга йөрәкләребезне ачкан, безгә яхшылыкны яманлыктан, хакыйкатьне ялганнан аерырга мөмкинлек биргән һәм безне хакыйкать юлыннан алып барганы өчен Аллаһыга мактау булсын.***

Әйе, Аллаһы Тәгалә безгә Үзенең дине – Ислам, ягъни «тынычлык» һәм «тыңлаучанлык» аша бәхетле булырга мөмкинлек бирде. Без, мөселманнар, Ислам динен кабул итеп, Аллаһыга буйсынабыз һәм Аның ризалыгына омтылабыз. Әйе, хакыйкать юлы авыр, анда күп сынаулар һәм кыенлыклар бар.

Ни өчен мөселманнар бер-берсенә Ислам динен тотарга комачаулыйлар? Ни өчен алар көферлек һәм ширек белән көрәшү урынына үз кардәшләренә каршы торалар? Ислам моны тыя бит...

Бу сорауның сәбәпләре күп:

## Без Коръән аятьләре турында фикерлибезме?

**«Әгәр дә Без бу [кадәрле әһәмиятле мәсьәләләрне эченә алган] Коръәнне бер тауга иңдергән [һәм аңа да сезгә биргән кебек акыл биргән] булсак, син аны Аллаһыдан куркудан буйсынган хәлдә яргаланганын күрер идең. Бу мисалларны Без кешеләргә фикерләсеннәр дип китерәбез».**

«Әл-Хәшр / Җыен», 59:21

**«Һичшиксез, төн белән көннең [бер-берсе артыннан килеп һәм артып-кимеп] алмашуларында һәм Аллаһының күкләрдә һәм җирдә яраткан [тиңсез] нәрсәләрендә тәкъвалык ияләре булган кешеләр өчен [Яратучының барлыгына, берлегенә, чиксез көченә һәм өстен хикмәтенә ап-ачык ишарә ясаган бик күп] билгеләр бар».**

«Юныс», 10:6

**«Дөнья тормышының хәле – бер су кебек: Без аны күктән иңдердек һәм кешеләр белән терлекләр туенган туфракның үсемлекләре, аның сәбәпле, бер-берләренә [үрелеп] бәйләнделәр. Туфрак матурлыкка күмелеп бизәлгәч, аңарда яшәүчеләр исә үзләрен [өлгергән уңышлардан файдаланугa] көчләре җиткән кешеләр дип санаган бервакытта, төнлә яки көндез [боз, кырау, чикерткә, күсе һәм давыл кебек газапларыбыз белән бәйле] әмеребез аңа [җиргә] килде. Без аны [агачларын, үләннәрен һәм игеннәрен], гүя әле генә булмаганнар кебек, тамырыннан куптарылган бернәрсәгә әйләндердек. Фикер йөрткән кешеләр өчен Без аятьләребезне әнә шулай тәфсилләп аңлатабыз».**

«Юныс», 10:24

## Динне тулысынча аңларга тырышабызмы?

Кеше белмичә яисә оныту аркасында дөрес булмаган гамәлләр кыла ала. Ләкин бу аның эшләрен акларга сәбәп булып тормый. Аятьләрне һәм хәдисләрне үзенең белем дәрәҗәсеннән генә чыгып аңлаткан, шул рәвешле башкаларны адаштырган һәм Исламны дөрес итеп аңлатмаган кешеләр дә бар. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Аллаһы, фәрештәләр һәм гыйлем ияләре Аннан башка гаделлек урнаштыручы һичбер илаһ булмаганына шаһитлык итәләр. Ул – [җиңелмәс] Бөек һәм Хикмәт иясе. Аннан башка һичбер илаһ юк».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:18

## Мөселманнар бер-берләренә карата мөселманга караган кебек карыйлармы?

Без нәрсә күрәбез? Булырга тиешленең капма-каршысы: мөселман кардәшебезнең берәр ялгышын күреп, берәр төрле киңәш бирсәк, ул аны кабул иткәнче, башта үзен аклый башлый. Яисә, икенче бер мөселманга: «Син безнең төркемнән түгел», – дип яла ягалар. Бер мөселман икенчесенә хыянәт иткән очраклар юкмы? Кардәшенә авыр чакларда булышмый калганы юкмы? Ләкин Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә болай дип әйтә: «Бер-берегездән көнләшмәгез, товар бәясен арттырмагыз, бер-берегез белән бәхәсләшмәгез, әй, Аллаһы коллары, кардәшләр! Мөселман – мөселманның кардәше (туганы): ул аны җәберләми, ярдәменнән калдырмый һәм алдамый (имам Әл-Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

## Бу дөньяга карата мәхәббәт

Әлбәттә, пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм өчен Ахирәт тормышы бер башка өстен булган. Бүгенге көн мөселманнары дөнья тормышына сеңә башлады. Хәтта, кайберләребезнең шәригать бурычларын үтәр өчен вакытыбыз җитми башлады. Әмма бу дөньяның гына зиннәте булган әйберләр кешегә ике дөнья өчен дә файда булып тормаска мөмкин. Хәсән Әл-Басри рәхмәтуллаһи галәйһи: «Дөнья тормышы иманлы кеше өчен нинди яхшы урын. Ул аннан кирәкле әйберләр өчен генә тиешле көчен куя, үзенә җитәрлек ризык таба һәм оҗмахка таба бара. Дөнья тормышы һәр явыз һәм икейөзле өчен начар урын. Ул көне-төне җәһәннәмгә барыр өчен эшли», – дип әйткән (Әхмәд бине Хәнбәл, «Китәбүз-Зөхд»). Бу дөнья тормышы кешене алдап, үзен ул әзләгән мәңгелек бәхет урыны булараk күренергә тырыша.

Ә соң бу вакытта нишләргә? Безнең бу хәлебезне төзәтеп буламы? Була! Без үзебездән башларга тиеш, чөнки Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

**«Һичшиксез, алар [кешеләр] үз нәфесләрендә булганны алмаштырмый торып, Аллаһы кешеләрдә булганны алмаштырмый».**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:11

Бу хасталыклардан чыгу юллары берничә:

1) уйлану-фикерләү; эшләребезне контрольдә тоту;

2) белем алу;

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Без синнән алда да [кешеләргә пәйгамбәр итеп] ирләр җибәргән идек, шуларга вәхи иттек. Әгәр сез белмәсәгез, зикер ияләреннән сорагыз».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:43

3) Коръәни Кәримгә һәм Аллаһы Расүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләменең сөннәтенә ныклап иярү;

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыга итагать итегез, Расүлгә һәм үзегездән булган хөкем ияләренә итагать итегез. Әгәр сез Аллаһыга һәм Ахирәт көненә ышансагыз, [дингә кагылышлы] берәр нәрсә турында [үзара] сүз көрәштергән очракта, аны Аллаһыга һәм [үзе яныгызда булса] Расүлгә кайтарыгыз. Бу хәерлерәк, [Ахирәттә булачак] нәтиҗә ягыннан да яхшырак».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:59

4) мөселманнарны дуслаштыру;

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

**«Һичшиксез, мөэминнәр – кардәшләр. Шуңа күрә кардәшләрегезне татулаштырыгыз. [һәр эштә булганы кебек, дин кардәшләрегезнең араларын якынайтуны да җиңелгә алуда] Аллаһыдан куркыгыз, бәлки, рәхмәт ителерсез».**

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:10

5) бер-беребезгә искә төшерү;

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

**«Ләкин үгет бирүне дәвам ит, чөнки вәгазь иман китергән кешеләргә файда бирә».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:55

6) Ахирәт тормышы өчен яхшы гамәлләрне арттырырга тырышу;

**«Ул – [сиңа макталган] соңгы йорт. Без аны җирдә тәкәбберләнмәгән һәм бозыклык теләмәгәннәрнеке итәчәкбез. Ул [күркәм] нәтиҗә [әмерләрен тотып, тыюларыннан тыелып, Аллаһы Тәгаләнең газабыннан сакланган] тәкъвалык ияләренеке [булачак]».**

«Әл-Касас / Кыйсса», 28:83

7) сабыр булу.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

**«Ий иман китерүчеләр! Сабырлык һәм намаз аша [Аллаһы Тәгаләдән] ярдәм сорагыз. Һичшиксез, Аллаһы сабыр итүчеләр белән».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:153

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсем килә: без, мөселманнар, – Ислам диненең көзгесе икәнебезне онытмасак иде. Без үзебезне мөселманнар арасында да, мөселман булмаганнар арасында да ничек тотуыбызга карап, кешеләр Ислам дине турында сөйләшәчәкләр, фикер йөртәчәкләр.

■ **Раушан хәзрәт ХӨСНЕТДИНОВ,**
Актаныш авылы 2 мәхәллә имам-хатыйбы



Фото: shutterstock.com

# Бәлгам бине Багура

*(Циклның дәвамы)*

Муса галәйһиссәлам заманында яшәгән Бәлгам бине Багура тирән белемнәргә һәм хикмәтләргә ия булган. Аның кылган догасын Аллаһы Тәгалә шулвакытта ук кабул иткән. Әмма, Аллаһының аңа карата киң рәхмәте булуга да карамастан, ул моның өчен Яратучысына бер тапкыр да шөкер итмәгән. Киресенчә, бу зур бәхетне ул, Аңа итагатьсезлек һәм буйсынмаучанлык күрсәтеп, Аллаһы разый булмаган гамәлләрендә файдаланган. Бәлгам бине Багура Муса галәйһиссәламгә һәм аңа иярүчеләргә ләгънәт кылган, шул сәбәпле Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм ителгән.

Коръәндә бу вакыйгаларга карата ачыктан-ачык булмаган түбәндәге күрсәтмәләр бар:

**"[Расүлем!] Аларга [яһүдиләргә һәм башка кешеләргә рухи кыйммәтләрне шәхси мәнфәгатендә кулланган Бәлгам бине Багура исемле] затның хәбәрен укы. Без аңа аятьләребезне бирдек, әмма ул алардан тайпылды, бу сәбәптән [иманлы була торып, аңа иярә алмаган] шәйтан аңа иярде, һәм ул адашканнардан булды. Әгәр Без [аның аятьләрдән файдалануын] теләсәк, шулар аркылы аны [галимнәр дәрәҗәсенә] күтәргән булыр идек. Ләкин ул [гади] туфракка сырышты һәм [кабиләсе күзендә яхшы күренер өчен нәфесенең] начар теләгенә иярде. Аның хәле этнеке кебек: [аны куар өчен] өстенә барсаң да, телен чыгара, аны [үз хәлендә] калдырсаң да, телен чыгара. Бу – [Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сыйфатларын Тәүратта укыганнан соң, белә торып] аятьләребезне ялган санаган ул кавемнең кыйссасы. Бу кыйссаны сөйләп тор, – бәлки, алар уйланырлар [һәм бу кешенең хәленә төшмәсләр]".**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:175-176

Күрәсез, Бәлгам бине Багура тарихы кыскача әлеге аятьләрдә тасвирлана, шулай да тәфсирләргә һәм китапларга да кергән.

Риваятьләрдә әйтелгәнчә, Муса галәйһиссәлам бер тәкәббер халыкка каршы яуга әзерләнеп, Кенанның уллары җиренә – Шамга килеп кергән. Халык ярдәм сорап Әл-Бәлка шәһәре авылларының берсендә торган Бәлгам бине Багура янына килгәннәр:

– Ий Бәлгам! Муса бине Гыймран үзенең гаскәре белән безне үтерергә, илебездән куып чыгарырга һәм безне Исраил уллары кулына тапшырырга дип килде. Әмма безнең башка торыр җиребез юк! Ул чагында безгә кайда яшәргә соң? Синең догаларың кабул була, шуңа бу авыр хәлдән имин котылуыбызны сорап Аллаһыга мөрәҗәгать итсәң иде.

Адашу юлына төшкәнче Бәлгам бине Багура Муса галәйһиссәламнең пәйгамбәрлегенә иман китерүчеләрнең берсе булган. Шуңа күрә бу тәкъдимгә җавап итеп, ул болай дигән:

– Ул – Аллаһының илчесе һәм барлык фәрештәләр, иман әһелләре – барысы да аның белән. Мин аларга каршы ничек дога кыла алыйм?!

Әмма халык үз сүзләрендә нык торып, Бәлгамның хатыны янына барырга карар кылганнар. Бәлгамны бу эшкә күндерә алса, хатынына кыйммәтле бүләкләр вәгъдә иткәннәр. Хәер, алар дөнья зиннәтләре белән Бәлгамның үзен дә кызыктырганнар. Һәм Бәлгам... ризалашкан.



Фото dumrt.ru сайтыннан алынды

Шулай итеп, Бәлгам бине Багура качырына атланып, Хусбан тавына чыгып киткән. Әмма беркадәр ара узгач, аның качыры җиргә утырган һәм алга барырга теләмәгән. Хайванын кыйный һәм сүгә башлагач, качыры тагын бераз араны үткән, әмма арып янә җиргә сузылып яткан. Шулчак хайван телгә килеп сөйләшә башлаган:

– Ий, Бәлгам! Син кая барасың? Минем алдымда фәрештәләр тора һәм алар миңа узып китәргә ирек бирмиләр. Син Аллаһының пәйгамбәре һәм иман әһелләренең каргышын алырга дип барасыңмы әллә?

Әмма Бәлгам бине Багура артык масаеп һәм тәкәбберлек күрсәтеп, хайванның аның белән сөйләшә башлавына да игътибар итмичә качырны кыйнавын дәвам иткән.

Аллаһы Тәгалә качырга юлны ачкан һәм ул алга ыргылган. Ниһаять, качыр хуҗасын Хусбан исемле тау башына кадәр алып менгән. Бәлгам бине Багура шушы җирдә Муса галәйһиссәламгә һәм аның гаскәренә ләгънәт булсын дип дога кылган. Әмма Аллаһы Тәгалә аның телен үз халкына каршы борган. Аллаһының бу тәккәббер бәндәсе нинди генә ләгънәт укымасын, алар барысы да аның кавемдәшләренә барган, ә изге догалары исә Муса галәйһиссәлам хисабына кабул ителгән. Бәлгам тарафыннан ләгънәт кылынуын күреп, кавемдәшләре аңа ябырылганнар:

– Ий, Бәлгам! Син нәрсә эшлисең? Алар өчен син изге дога кыласың, ә безгә ләгънәт кылырга чакырасың.

Ул кавемдәшләренә болай дип җавап биргән:

– Мин моны үз ихтыярым белән эшләмим. Минем телем белән Раббыбыз идарә итә.

Шуннан соң аның теле авызыннан атылып чыгып, күкрәк турысына җитеп асылынып калган. Бәлгам бине Багура халкына таба борылып болай дигән:

– Мин хәзер дөнья тормышын да, Ахирәтне дә югалттым. Бары хәйлә һәм мәкерлек кенә калды.

Шуннан соң ул үз халкын җиңүгә ирешү өчен кулланырга кирәк булган хәйләкәр гамәлләргә өйрәтә башлаган.

Бу риваятьтә фикер йөртүче кешеләр өчен кыйммәтле сабак бар: үз юлында Аллаһының ачык могҗизаларына юлыгып та, хакыйкать юлына иярмәгән кешенең ахыры менә шулай тәмамланачак. Бәлгам бине Багура үрнәге бар көчен ислам белән көрәшүгә багышлаган имансыз галимнәрнең торышын күз алдына китерергә ярдәм итә. Имансыз бәндәләр дә шулай ук үз файдалары хакына Аллаһының динен бозалар һәм иманнарын дөнья байлыкларына, дан-шөһрәтләргә алмаштыралар.

Әлеге нәсыйхәттә китерелгән аятьләр, һичшиксез, Бәлгам бине Багура турында сөйлиләр, әмма андагы хөкемнәр бары бер генә кешегә түгел, ә аңа охшаган башка барлык кешеләргә дә кагыла. Үзенең тәкәбберлеге һәм дөньяга хирыслыгы сәбәпле, шәйтанга ияреп адашу юлына баскан Бәлгам Аллаһының могҗизаларын санга сукмыйча, телен чыгарган эт дәрәҗәсенә төшкән кешене гәүдәләндерә. Гыйлем һәм хакыйкать юлыннан тайпылган һәркемнең торышы шундый булачак, ул үзенең нәфесе һәм теләкләренә иярәчәк, дип сурәтли Раббыбыз аны искә алган аятьләрдә.

Бер риваятьтә әйтелгәнчә, элек Бәлгам бине Багура өчен билгеләнгән җәннәт хәзер мәгарәдә яшәүчеләрнең етенә биреләчәк. Әлеге мисал никадәр дәрәҗәдә гыйбрәт булып тора! Бөек галим була торып, Бәлгам бине Багура, телен чыгарып, эт дәрәҗәсендә калып, Раббыбызның дусларына каршы көрәшүчеләр арасында үз урынын алганнан соң, Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм ителә. Әмма Кытмир кушаматлы гапгади эт мәгарәдә яшәүчеләр, ягъни Аллаһының дуслары арасында лаеклы урынын алып, җәннәткә ия булучылар дәрәҗәсенә ирешәчәк.

Раббыбыз безне төрле мөмкинлекләр һәм теләкләр белән сыный, әмма карарларны без үзебез кабул итәбез. Тугры яки имансыз булу – һәр акыллы кеше Аллаһының рәхмәте белән үз юлын сайлый. Кем өчендер гөнаһ һәм көферлектән торган татлы, әмма кыска вакытлы бәхет күңеленә якынрак, ә кемгәдер, авырлыклар белән тулган булуга да карамастан, хакыйкать кыйммәтрәк булып тора. Раббыбыз безне әлеге дәрестән сабак алучылардан насыйп әйләсә иде. Ул безне явызлыктан һәм динне бозучы кабахәт галимнәрнең явызлыгыннан Үзе сакласын һәм безгә Әһле Сөннәт галимнәре юлыннан тайпылмауны насыйп әйләсен! Әмин!

■ **Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
Татарстан Республикасы мөфтие

# Диндә ныклык сорыйк


Фото: shutterstock.com

***Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Раббыбызга барча мактауларыбыз булсын. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез ирешсен. Пәйгамбәребезнең сахәбәләренә, табигыйннәргә, тәбге-табигыйннәргә, хәер-дога, сәламнәребез булсын.***

Мөхтәрәм кардәшләр! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән нигъмәтләре бихисап. Болар – кояш, сулаган һавабыз, һәр сулыш алуыбыз, акыл, сәламәтлек, ашаган ризыгыбыз, кигән киемнәребез һәм безнең әйләнә-тирәбездә булган бик күп башка нигъмәтләр. Аллаһы Тәгалә «Ән-Нәхл» сүрәсендә болай дип әйтә:

**«Аллаһының [сезгә биргән бөтен] нигъмәтләрен саный башласагыз, аларны санап бетерә алмассыз».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:18

Аллаһы Тәгалә безгә биргән нигъмәтләрнең иң кыйммәтлесе иман булып тора. Аллаһы Коръәннең «Ән-Ниса» сүрәсендә болай дип әйтә:

**«Аллаһы сезгә [белмәгән нәрсәләрегезне] бәян итәргә, сезне дә сездән элгәреләрнең [Нәбиләр һәм изгеләрнең] юлларына күндерергә һәм сезнең [ялгышларыгыз өчен кылган] тәүбәгезне кабул итәргә тели. Аллаһы – [һәрнәрсәне] Белүче, Хикмәт иясе».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:26

Галәмдәге бөтен мәхлукат, бөтен тереклек ияләре үзләрен бар кылган Аллаһы Тәгаләне үз телләре белән зикер итә, тәсбих кыла, Аңа мактау сүзләрен әйтә. Бу хакта Раббыбыз Коръәннең «Әл-Исра» сүрәсендә болай дип әйтә:

**«Җиде [кат] күкләр белән җир һәм аларда булганнар Аңа тәсбих әйтеп торалар. [Диңгездәге балыклардан алып, һавадагы кошларга кадәр] Аны мактау белән мактамаган һичбер нәрсә юк, ләкин [телләрегезнең төрлелеге, фикерләвегезгә киртә булган бер гафләттә тотылуыгыз сәбәпле] сез аларның тәсбихләрен аңламыйсыз. Һичшиксез, Ул – Мәрхәмәтле һәм Гафу итүче».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:44

Инсан акыллы, камил зат итеп яратылган. Аллаһы безгә биргән иман нигъмәте өчен Раббыбызны искә алу, мактау, Аллаһыга шөкер итү – инсанның бурычы. Безне даими исенә төшереп торучы һәм һич кенә дә онытмаучы Аллаһыны искә алып зикер итү – кешеләрнең иң мөһим вазифаларының берсе. Аллаһы «Локман» сүрәсендә болай дип әйтә:

**«Без Локманга хикмәтне [сүздә һәм эштә урынлы өстен белемне] «Аллаһыга шөкер ит!» – дип бирдек. Кем дә кем шөкер итсә, үз файдасына шөкер иткән булыр, кем дә кем инкяр итсә, һичшиксез, Аллаһы – [беркемнең дә ярдәменә мохтаҗ булмаучы] Бай, Мактауга лаеклы».**

«Локман», 31:12

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«Мине искә алыгыз, Мин дә сезне искә алырмын. Миңа шөкер итегез, [әмеремә буйсынмыйча, нигъмәтләремне күрмәгәндәй] Миңа карата шөкерсез булмагыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:152

Кайберәүләр, дин юлына баскач, үзен башкалардан өстен күрә. Әлбәттә, Ислам дине бу гамәлне хупламый. Мөселманга башка кешеләрне яхшылык кылуга өндәп, аларны нәсыйхәтләп, ләкин үзен җәннәткә лаек булдым, дип хис итү дөрес булмас, чөнки без гомеребез дәвамында тырышып иманыбызны саклап яшәргә тиешбез. Без гөнаһны гөнаһ дип күрергә, тәкәбберлектән, горурланудан читләшергә тиеш.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә: «Тәкәбберлек сыйфаты Минем киемем һәм шулай ук олуглык сыйфаты да Минем киемем. Кем дә кем аларның берсен Миннән тартып алырга теләсә, Мин аны җәһәннәм утына атачакмын», – дип әйтә» (имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Тәкәбберлек сыйфатыннан котылу өчен, Аллаһыга дога кылырга кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһыга болай дип дога кыла иде:

رَبِّ أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْكَسَلِ وَسُوءِ الْكِبَرِ، رَبِّ أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابٍ فِي النَّارِ وَعَذَابٍ فِي الْقَبْرِ

«Рабби әгуузү бикә минәл-кәсәли вә сүү’ил-кибәри, Рабби әгуузү бикә мин газәәбин фин-нәәри вә газәәбин фил-кабри».

Мәгънәсе: «Раббым Аллаһы! Мин Сиңа ялкаулыктан, тәкәбберлек сыйфатыннан, җәһәннәм утыннан һәм кабер газабыннан саклауны сорап сыенам» (имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Мөселман кешесе Аллаһы Тәгаләдән диндә булмаган кешеләр өчен, аларны туры юлга күндерүне, җәһәннәм утыннан саклауны һәм җәннәткә кертүне сорап дога кылырга тиеш.

Ислам дине кешеләрне дөнья эшләре белән бәйле нигъмәтләргә: ризыкка, саулык-сәламәтлеккә, байлыкка, эш урынына канәгать булырга өнди. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм канәгать булуның фазыйләтен аңлатып болай дип әйтә: «Кем иртә белән иминлектә, саулыкта, бер көнлек ризыгы булган хәлләттә йокыдан уянса, ул җир йөзенең бөтен байлыгына ия булган кеше кебек булыр» (имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан).

Әгәр дә кеше матди яктан үзеннән түбәнрәк кешеләргә караса, аның күңеле үз хәләтеннән канәгать кала һәм ул Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләргә шөкер итә башлый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Сездән югары булганнарга түгел, ә сездән түбән булучыларга карагыз. Бу сезгә Аллаһының нигъмәтләрен ким итеп күрмәүдә ярдәм итәчәк».

Аллаһы Тәгалә адәм баласына башта Раббысына, аннары ата-анасына шөкер итәргә куша, чөнки баланы дөньяга Аллаһының рәхмәте белән әти-әнисе тудыра. Безгә Раббыбыз каршысына барачагыбызны онытмау, хәерле гамәлләребезне арттыру, һәрчак шөкердә булу тиешле.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«Сез яхшы гамәлләргә ашыгыгыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:148

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм көненә йөзләгән мәртәбә болай дип дога кылган:

يَا مُقَلِّبَ الْقُلُوبِ ثَبِّتْ قَلْبِي عَلَى دِينِكَ

«Йәә мүкаллибәл кулүүби сәббит кальбии галәә дииник».

Мәгънәсе: «Йә, калебләрне әйләндерүче, минем калебемне Синең динеңдә нык ит».

Шулай ук Пәйгамбәребез мондый дога да кылган:

اللَّهُمَّ مُصَرِّفَ الْقُلُوبِ صَرِّفْ قُلوبَنَا عَلَى طَاعَتِكَ

«Аллааһүммә мусаррифәл кулүүби сарриф кулүүбәнә галәә таагәтик».

Мәгънәсе: «Йә, Аллаһы, калебләрне юнәлтүче, безнең калебләребезне Сиңа итагать кылуга юнәлт» (имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Һәм без дә шушы догаларны кылып, Аллаһы Тәгаләдән тәкъвалык ияләреннән булуыбызны сорыйк.

Әбү Гамр Суфьян бине Габдулла Сәкафи радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Бервакыт мин: «Әй, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм, миңа Ислам турында мин синнән соң беркемнән дә сорамаслык сүзләр әйт», – дидем. Ул: «Мин Аллаһыга ышандым», – дип әйт тә, аннары тугры бул!» – диде» (имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Мөхтәрәм кардәшләр! Раббыбыз Үзенең кушканнарын үтәп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең юлында булып, динебездә тугры булуны насыйп итсен!

■ **Рамил хәзрәт ХӨСНЕТДИНОВ,**
Бөгелмә районы һәм шәһәре имам-мөхтәсибе

# Холыкны яхшырту өчен укыла торган догалар

***Нәрсәгә дә булса ачу килү, кызып китү адәм баласы өчен гадәти хәл, чөнки кешенең Аллаһы тарафыннан көчсез итеп яратылганын да, еш кына хаталануын да беләбез. Әмма кеше үзенең холкын белсә, тәкәбберлеген читкә куеп, хатакимчелекләрен таный алса, нәфесенә дә, шәйтан вәсвәсәсенә дә бирелмәс.***

Расүлебез нәфесебез белән көрәшүне зур тырышлык дип атаган. Чыннан да, кешенең үз кимчелекләрен белеп, аларны танып, холкын камилләштерергә тырышуы – кешенең Аллаһы юлында тырышлык кылуы була. Әлбәттә, бу эшне Раббыбызның ярдәменнән башка булдырып чыгу кыен. Шуңа да, мөэмин-мөселман кешесе, һәрвакыттагыча, һәр эшен дога кылу белән башлый, һәм, гомумән тормышын дога белән алып бара. Биредә холыкны яхшырту, ачу чыкканда үзеңне тыю, саранлык кебек яман гадәттән саклану өчен кылына торган догалар китерелгән.

### Күзгедән караганда укыла торган дога:

اَللّٰهُمَّ أَنْتَ حَسَّنْتَ خَلْقِي فَحَسِّنْ خُلُقِي

“Аллааһуммә әнтә хәссәнтә халькый фәхәссин хулүкый”.

«Йә Аллаһы! Сурәтемне күркәм кылган кебек, холкымны да күркәм әйлә».

### Саранлыктан саклауны сорап дога кылу:

اَللّٰهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْهَمِّ وَالْحَزَنِ وَمِنَ الْعَجْزِ وَالْكَسَلِ وَمِنَ الْجُبْنِ وَالْبُخْلِ وَمِنَ الْمَأْثَمِ وَالْمَغْرَمِ وَمِنْ غَلَبَةِ الدَّيْنِ وَقَهْرِ الرِّجَالِ

«Аллааһуммә иннии әгуузү бикә минәл-һәмми вәл-хәзән, вә минәл-гаҗзи вәл-кәсәл, вә минәл-җубни вәл-бухли, вә минәл-мәә-ҫәми вәл-мәгърам, вә мин галәбәтид-дәйни вә каһрир-риҗәәл!»

“Йә Аллаһым! Сиңа гына сыенамын! Синнән генә ярдәм сорыймын. Күңел төшенкелегеннән, көчсезлектән һәм куркудан, саранлыктан һәм вакчыллыктан, бурычлы булудан һәм адәмнәрнең золымыннан Сиңа гына сыенамын!”

### Ачу чыкканда укыла торган дога:

أَعُوذُ بِاللّٰهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ

“Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим”.

“Аллаһының рәхмәтеннән мәңгегә куылган шәйтанның начарлыгыннан Аллаһыга сыенам”.

### Ачуланганда укый торган дога:

Кеше көндәлек тормышта төрле сәбәпләр аркасында кәефсезләнер, кызып китәр, ачуы чыгар. Бу халәте кешегә эштә дә комачау итәр. Мондый вакытта түбәндәге дога укылыр:

اللّٰهُمَّ اغْفِرْ لِي ذَنْبِي وَ اَذْهِبْ غَيْظَ قَلْبِي وَأَجِرْنِي مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمْ

“Аллааһуммәгъфир лии ҙәнбии вә әҙһиб гайҙа кальбии вә әҗирнии минәш-шәйтаанир-раҗиим”.

“Аллаһым, гөнаһларымны мәгъфирәт кыл, йөрәгемнең ачуын бетер һәм мине шәйтанның явызлыгыннан сакла”.

Әгәр ачуы узмаса, мөмкинлек булса, тәһарәт алып, ике рәкәгать намаз укырга һәм "Әл-Инширах" сүрәсен укырга кирәк. Югарыда китерелгән доганы да кабатларга мөмкин.

# Сәфәр белән бәйле догалар

Без һәркөнне үз эшләребез белән йортыбыздан чыгабыз, бик еш ерак яки якын сәфәрләргә кузгалабыз. Барасы юлы озын яки кыска булуына карамастан, мөэмин-мөселман кешесе сәфәрен дога белән башларга тиеш. Бу безнең Раббыбызга тәвәккәл итүебезне, Аның гына ярдәменә һәм рәхмәтенә өметләнүебезне белдерә. Дога – мөселман кешесенең юлдашы ул. Шуңа да һәрдаим барасы юларыбызны дога белән яктыртыйк, киң кылыйк. Биредә өйдән чыкканда, кергәндә, транспорт чаралапына утырганда, гомумән, сәфәргә чыкканда кылына торган догалар китерелгән.

### Өйдән чыкканда укыла торган дога:

بِسْمِ اللّٰهِ تَوَكَّلْتُ عَلَى اللّٰهِ وَلَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللّٰهِ

“Бисмилләһи тәвәккәлтү галәллааһи вә ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләәһ”.

«Аллаһының исеме белән Аллаһыга тапшырылдым, Аңа ышандым. Көч һәм куәт бары тик Аллаһыдандыр».

### Өйгә кергәндә укыла торган дога:

بِسْمِ اللّٰهِ وَلَجْنَا، وَبِسْمِ اللّٰهِ خَرَجْنَا، وَعَلَى رَبِّنَا تَوَكَّلْنَا

“Бисмилләһи вәләҗнәә, вә бисмилләһи харәҗнәә, вә галәә раббәнәә тәвәккәлнәә”.

«Аллаһының исеме белән кердек һәм Аллаһының исеме белән чыктык, Раббыбызга тапшырдык».

(Моны әйткәннән соң, кергән кеше өйдәгеләргә сәлам бирергә тиеш).

### Транспорт чарасына утырган вакытта һәм берәр йортка кергәндә укыла торган дога:

اَللّٰهُمَّ اَنْزِلْنِى مُنْزَلًا مُبَارَكًا وَأَنْتَ خَيْرُ الْمُنْزِلِينَ

“Аллааһуммә әнзилнии мүнзәлән мүбәәракән вә әнтә хайрульмүнзилиин”.

«Йә, Раббым, мине мөбарәк җиргә иңдер. Син иң хәерле иңдерүче».

### Юлга чыкканда укыла торган дога:

Автомобильгә утырып киткәндә, яисә үзе руль артына утырганда, «Бисмилләһ» әйтелер, өч, биш яисә җиде мәртәбә “Аятел-Көрси” укылыр һәм урыннан кузгалып кителер.

Пәйгамбәребез юлга чыкканда шулай дога кылган:

اللّٰهُمَّ إِلَيْكَ تَوَجَّهْتُ وَبِكَ اعْتَصَمْتُ اللّٰهُمَّ اكْفِنِى مَا أَهَمَّنِى وَمَا لَا أَهْتَمُّ لَهُ اللّٰهُمَّ زَوِّدْنِى التَّقْوَى وَاغْفِرْ لِى ذَنْبِى وَوَجِّهْنِى لِلْخَيْرِ أَيْنَ مَا تَوَجَّهْتُ

“Аллааһуммә иләйкә тәвәҗҗәһтү вә бикәгътәсамтү. Аллааһуммә әкфинии мәә әһәммәнии вә мәә ләә әһтәммү ләһү. Аллааһуммә зәввиднит-тәкъвә вәгъфир лии ҙәнбии вә вәҗҗиһнии лил-хайри әйнә мәә тәвәҗҗәһтү”.

“Аллаһым! Сиңа юнәлдем, Сиңа сыендым. Аллаһым! Шикле һәм шиксез нәрсәләрдән миңа таяныч бул. Тәкъваны миңа ризык әйлә, Аллаһым! (ягъни Сиңа гыйбадәтләр кылып, рухыма азык табыйм) Аллаһым! Гөнаһларымны гафу ит һәм кая гына китсәм дә, мине һәрвакыт хәерле эшләргә юнәлт, йә, Раббым!”

■ Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде



Фото: shutterstock.com

# “Казан басма” шрифты нигезендә Коръән басмага әзерләнә

***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенә “Казан басма” исемле махсус эшләнгән дизайнлы компьютер шрифты нигезендә җыелган Коръән басмасының электрон нөсхәсе тапшырылды. Проектның цифрлаштырылган мәгълүматларын Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәрмәрә университетының “Илаһият” факультеты деканы, доктор, шрифтны төзүче Мөхәммәд Абайдан кабул итте.***




Фото: dumrt.ru сайтыннан алынды

Әлеге истәлекле вакыйга уңаеннан «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында матбугат очрашуы узды. Журналистларның сорауларына Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Мәрмәрә университетының “Илаһият” факультеты деканы, доктор, шрифтны төзүче Мөхәммәд Абай һәм Татарстан Республикасы мөфтие урынбасары, нәзарәтнең “Хозур” нәшрият йорты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин җавап бирделәр.

«Казан басма» исемле дизайнлы компьютер шрифты дөньякүләм танылган иске типографик оттискысы нигезендә ясалды. Аны файдаланып Коръәннең яңа «Казан басмасын» чыгару – мөфтиятнең Идел буе Болгар дәүләтендә ислам кабул ителүнең 1100 еллыгына әзерлек кысаларында иң зур һәм мөһим башлангычларының берсе.

– Бу эш моннан бик күп еллар элек үк башланырга тиеш иде, – диде Камил хәзрәт. – Билгеле булганча, “Казан басмасы” – мөселманнар тарафыннан типография ысулы белән бастырылган беренче Коръән ул. Мөселманнар арасында хәтта шундый гыйбарә бар: “Коръән Хиҗазда иңгән, Истанбулда язылган, Каһирәдә укылган, Казанда бастырылган!” “Казан басмасы”ның типографик шрифтын ислам дөньясы бик яратып кабул итә, шуңа күрә ул бөтен Җир шары буйлап тарала башлый. Әмма хаталар булу сәбәпле, Муса Бигиев һәм башка зур галимнәр басманы камилләштерергә хыяллана, 1909 елда Казанда бу уңайдан фикер алышу өчен 300 гә якын дин галиме җыела. Алар арасында Муса Бигиев, Әхмәтһади Максуди, Шәйхелислам Хәмиди кебек зур галимнәр була. Бу хакта иске имляда язылган «Тасхих ресми хат» китабыннан укып була. Галимнәр беренче җыелуда гына мәсьәләне хәл итеп бетерә алмый һәм азрак состав белән тагын бер атнадан җыела. Сөйләшүнең нәтиҗәсе буларак, бер комиссия оеша – “Казан басмасы”нда төзәтергә кирәк булган 57 урын табыла. Төрле сәбәпләрләргә бәйле (беренче чиратта, инкыйлаб чыгу сәбәпле) эш тәмамланмыйча кала.

Татар халкына аны башкарып чыгу нәкъ «1100 еллык» алдыннан насыйп була – бүгенге көндә яңа басылып чыгачак басманың текстларын Татарстан мөфтияте белгечләре тикшереп чыкты. Ул дөньякүләм кабул ителгән “Әр-рәсем Әл-Госмани” стандартларына туры киләчәк. «Казан басма» дизайнлы компьютер шрифты үзе исә ислам халыклары бик яратып өлгергән иске типографик оттискысы нигезендә ясалган. Шрифтны компьютерлаштыру һәм Коръән текстларын яңадан әлеге шрифт белән җыю бер ел дәвамында алып барылды.

Моңарчы Нәзарәтнең «Хозур» нәшрият йорты Коръән китапларын, 1803 елда чыккан Казан басмаларының аерым сүзләрен, фразаларын һәм аятьләрен компьютерда сканерлап, шрифтка сала торган була. Хәзер исә заманча компьютер шрифты ярдәмендә Коръән басмаларын төрле форматларда һәм югары сыйфатта чыгарырга мөмкин булачак. Матбугат очрашуында журналистларга иске һәм яңа «Казан басмалары» чагыштырып күрсәтелде һәм заманча шрифтның өстенлекләре күрсәтелде. Шрифт Коръән мосхафларын бастыруга яңа зур мөмкинлекләр ачачак, Коръән һәм китаплар бастыруның татар традицияләрен яңартуга һәм үстерүгә ярдәм итәчәк. Коръәннең «Казан басмасын» аның уникаль шрифты дөньякүләм танытты, шуңа күрә нәзарәт тарафыннан белгечләр алдында нәкъ шушы шрифтны торгызу мәсьәләсе куелды. Инкыйлабка кадәр дөнья күргән Коръәннең “Казан басмасы” башка басмалардан вертикаль хәрәкәләр кулланылу, тәнвиннәрнең аерылып торуы, саннарның язылышы һ.б. белән үзенчәлекле.

Коръәннең «Казан басмасы» үз вакытында Урта Азия, Төньяк Кавказда аеруча киң таралыш алуын дәлилләп, журналистларга мисал итеп Чечня Республикасы башлыгы Рамзан Кадыйровның Казан басмасын яратып укуы видеода күрсәтелде. Ә шрифтны төзүче Мөхәммәд Абай исә заманында Төркиягә «Казан басмасыннан» башка бернинди мосхафлар кертелмәве хакында, татарларның дөньякүләм мөселман мәдәниятендә тоткан олы урыны хакында сөйләде.

– Казанда беренче Коръән басмасы 1803 елда чыкса, Истанбулда ул 1872-73 елда гына чыга! – дип билгеләп узды Мөхәммәд бәй. – Ягъни татарлардан соң 70 ел узгач кына! Истанбул мөселманнары өчен Казан басмасы шуның белән дә әһәмиятле: архивларда күренгәнчә, Госманлы империясенә башка илләрдә бастырылган Коръән китаплары кертелмәгән, бары тик Казан басмаларына гына таратылу өчен рөхсәт булган. Шуңа күрә бүген дә безнең галимнәр арасында еш кына Коръәннең Казан басмасын очратырга мөмкин. Шушы олы мираска яңа сулыш өрү – минем өчен зур дәрәҗә.

Бүгенге көндә дә Коръәннең яңа Казан басмасы дөнья күләмендә таралыш алыр дигән өмет бар, чөнки ул кабул ителгән халыкара стандартларга туры киләчәк, ягъни Китап 604 биттән, ә һәр бит 15 юлдан торачак. Моны башкару өчен Нәзарәтнең тәҗрибәсе бар: моңарчы 2017 елда «Хозур»да бастырылган Коръән китабы Рәсәйдә беренче тапкыр халыкара стандартларга туры килә дигән Шәһадәтнамәгә лаек булган иде инде. Шәһадәтнамә бирелгәч, Нәзарәттә әзерләнгән Коръән китабы мөселман дөньясында зур кызыксыну уятa: ул Төркиядә, Үзбәкстанда һәм Белоруссиядә бастырылды. Барлыгы «Хозур»да Коръән биш тапкыр 30 меңнән артык гомуми тираж белән чыкты.

Шул рәвешле, ТР мөселманнары Диния нәзарәте Коръән бастыруның татар традицияләрен кайтарды, Рәсәйдә Коръәнне дөрес аңлау өчен заманча нигез булдырды һәм халыкара мәйданда Коръән бастыру буенча эксперт буларак танылды.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# КОРЪӘН ЯРАТЫРГА ӨЙРӘТӘ

Ярату, мәрхәмәтле булу кешене зур дәрәҗәгә күтәрә торган сыйфат ул. Йөрәкнең каты булуы, беркемне дә яратмау, башкаларга начарлык теләү кешегә авырлык китерә. Андый кеше бәхетле була алмый. Ә үзенең янәшәсендә булганнарны яратучы, аларга ярдәм итеп яшәүче кеше һәрбер эшләгән яхшылыгыннан тәм табып яши. Коръән безгә әти-әниләребезне яратырга куша. Алар безнең бу дөньяга килүебездә сәбәпче булучылар. Әти-әниләребез безне кечкенә чагыбыздан ук яратып, кадерләп, кайгыртып яшәгәннәр, безнең барлык әйберләребез булсын өчен тырышканнар. Коръәндә ата-анага мәрхәмәтле булу хакында болай дип әйтелгән:

**“Раббың сезгә Үзеннән башкаларга табынмаска, ата-анага игелек [кылырга] әмер итте. [Ий кеше!] Аларның икесеннән берсе яки икесе дә синең янында картлыкка ирешсә, аларга [канәгатьсезлек белдереп]: «Уф!» – дип тә әйтмә. [Сүз-гамәлләре сиңа ошамаса да] Аларга кычкырма, күркәм сүз әйт”.**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:23

Бу аятьтә әти-әниләребезнең дә олыгаюлары, картлыкка ирешүләре хакында да әйтелгән. Раббыбызның: “...аларга [канәгатьсезлек белдереп]: «Уф!» – дип тә әйтмә”, – дигән сүзләре дә юкка гына түгел. Бала кечкенә чагында ата-ана, бигрәк тә әни кеше ярдәменә мохтаҗ була. Ул үз көче белән ашый да, йөри дә, киенә дә алмый, әмма һәрнәрсә вакытлар үтү белән ныгыган кебек, көннәрдән бер көнне бала да үсеп буйга җитә. Бу вакытта инде ул – көчле, ә аны тәрбияләп үстергән, аңа гомер биргән әти-әниләре олыгайган була. Нәкъ менә шушы вакытта кеше әти-әнисенә карата рәхмәтле булырга, аларны кайгыртырга тиеш. Әти-әнине үпкәләтү, рәнҗетү – зур гөнаһ. Балага кечкенәдән әлеге доганы укып, алар өчен Раббысыннан мәрхәмәтлелек сорау хәерле гамәл була. Коръән аяте булган әлеге дога болай дип яңгырый:

رَّبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيرًا﴿٢٤﴾

"Раббир-хәмһумәә кәмәә раббәйәәни сагыыйран".

**«Ий Раббым! Алар кечкенә чагымда мине [зур бер шәфкать белән] үстергәннәре кебек, Син дә аларга [бакый рәхмәтең белән] мәрхәмәт ит».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:24

■ Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде



Фото: shutterstock.com

# Коръән яхшыны яманнан аерырга өйрәтә

Коръәни Кәримне укып без нәрсәнең яхшы, нәрсәнең яман икәнен беләбез. Димәк, нәрсә эшләргә яраганы, нәрсәне ярамаганы хакында хәбәрдар булабыз. Диндә хәләл, харам дигән төшенчә бар. Хәләл – ярый торган, ә харам – ярамый торган дигән мәгънәне белдерә. Хәләл, харам сүзләрен без күбрәк ашый торган ризыкка карата кулланабыз. Шулай ук хәләл ризыкның, хәләл гамәлләрнең күңелебезгә тынычлык китергәнен, ә харам, ягъни ярамый торган ризыкларның, гамәлләрнең киресенчә, безгә тынычсызлык, борчу алып килгәнен аңлыйбыз. Шунысын да белик: хәләл дигән сүз – ул зыянлы дигәнне дә аңлата. Мәсәлән, дуңгыз ите, “бисмилләһи” сүзләре әйтеп чалынмаган башка хайван итләре, ризыкка кушылган төрле харам матдәләр кеше сәламәтлеге өчен зыянлы булып тора. Димәк, Аллаһы Тәгалә безне болардан юкка гына тыймаган.

Ислам дине нигезләрен камил рәвештә өйрәнү
ТҮЛӘҮСЕЗ
medrese.tatar
7 фән 124 дәрес
Онлайн «Татар мәдрәсәсе»
Теләсә кайсы вакытта һәм урында! Гади, аңлаешлы, һәркем өчен
Google Play
App Store

# Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать гакыйдәсе

*Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать гакыйдәсе – традицион Ислам инде ул. Ул – уттан котылганнарның карашлары, ягъни Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм, сәхабәләр, сәләфләр һәм Кыяматкә кадәр аларга ияргән галимнәрнең карашлары.*

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

**31**. Җәһәннәм һәм җәннәт инде бар, алар үз әһелләрен көтә.

Әһле Сөннәт һәм Җәмәгать тарафдарлары фикеренчә, җәһәннәм һәм җәннәт инде бар.

**32**. Иман – ул Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм аша Аллаһыдан ирештерелгәннәрнең хаклыгына калеб белән ышану, һәм шәһадәт кәлимәсе белән телдән исбатлау.

Имам Әбү Хәнифә фикеренчә, иман – ул Пәйгамбәребез динене калеб белән ышану, диндә шиксез билгеле булганнарны кабул итү һәм аларны, физик мөмкинлеге булса, телдән тәсдыйк итү. Димәк, кеше калебе белән иман китереп, аны, бөтен мөмкинлекләре була торып та, теле белән әйтмәсә, ул кеше башка кешеләр өчен һәм Аллаһы Тәгалә каршында да кяфер булып китәчәк.

**33**. Иман кимеми дә, артмый да: ул йә бар, йә юк. Иманның көче генә артырга яки кимергә мөмкин.

Иман – ул калеб белән иман нигезләренә ышану, һәм ул кими алмый, чөнки кеше иман рөкеннәренең берәрсенә ышанмый икән, ул мөэмин булудан туктый. Ә иманның көче һәм Аллаһыга якынаю дәрәҗәсе Аллаһының кануннарына буйсыну аша арта.

**34**. Калебендә иманы булган кеше үзе турында «Мин – хак мөэмин», дип әйтә ала.

Имам Әбү Хәнифә фикеренчә, кеше Аллаһыга ышана икән, ул үзенең ышануын «Мин – хак мөэмин» сүзләре белән беркетергә тиеш. Бу сүзләр мактану түгел, алар дини тәгълиматта шик булмаганны аңлаталар.

**35.** Зур гөнаһлар кылучы, әлеге гөнаһны хәләл дип санаганчыга кадәр, Исламнан чыкмый. Ялкаулык аркасында намаз укымаган кеше иманлы санала, һәм, әгәр ул намазга килмичә, үлеп китсә, аңа җеназа укыла.

Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать мөселманнары көферлекне һәм гөнаһларны аералар, шуңа күрә гөнаһлы бәндә, гөнаһлары булуга карамастан, иманлы санала, һәм аңа мөселманга кагылышлы барлык хөкемнәр дә карый: аның балалары мирас ала, аңа дога кылалар һәм аны мөселман зиратына җирлиләр. Көферлек исә – ул диндә шиксез беленгән нәрсәләрне кире кагу, мәсәлән, харам ризыкны хәләл санау яисә намазның фарызлыгын кире кагу.

**36.** Аллаһы көферлекнең бер генә төрен дә гафу итми, әмма кече һәм зур гөнаһларны гафу итәргә мөмкин. Гөнаһлы мөселманнар да иманлы, һәм алар җәһәннәмдә мәңге калмас.

Кеше кяфер булып үлсә, гафу ителмәс; әгәр Аллаһы теләсә, гөнаһлы кешене дә, гөнаһлары зур булуга карамастан, гафу итәр.

**37.** Тәкъва булса да, гөнаһлы булса да, мөэмин артыннан намаз уку дөрес. Иманлы булган хәлдә җан бирсә, җеназа намазы һәр мөэмин өчен укыла.

Имам Әбү Хәнифә фикеренчә, гөнаһлы мөэминнәр мөселман булып саналалар, һәм аларга ияреп укылган намаз дөрес була.

**38.** Фәрештәләр – Аллаһының коллары. Алар нурдан яратылган һәм Аллаһының бөтен әмерләрен кимчелексез һәм каршылыксыз үтиләр.

Фәрештәләрнең җенесе юк, алар арасында безгә исемнәре мәгълүм булганнары, мәсәлән, Җәбраил, Микаил һ.б. фәрештәләр һәм без исемнәрен белмәгәннәре дә бар.

Иблис уттан яратылган, һәм ул фәрештә түгел – җен.

**39.** Без Адәмнән алып, пәйгамбәребез Мөхәммәдкә кадәр җибәрелгән барлык пәйгамбәрләргә ышанабыз. Алар барысы да яхшылыкка өндәгән, яманлыктан тыйган һәм өммәтләре өчен иң яхшы үрнәк булган.

Мөселманнар Адәмнән алып, Пәйгамбәребезгә булган барлык пәйгамбәрләргә, барысының да Аллаһыдан вәхи алуларына, үзләренең өммәтләренә бары яхшылык кына теләүләренә һәм Аллаһының сүзен ирештерүдә нык көч куюларына ышаналар.

**40.** Пәйгамбәрләрне Аллаһы, пәйгамбәр булганчы да, пәйгамбәр булгач та, көферлектән, зур һәм кече гөнаһлардан саклый.

**41.** Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм – соңгы пәйгамбәр. Ул бөтен кешелек дөньясына җибәрелгән. Аңардан соң бернинди пәйгамбәр дә булмаячак. Соңгы пәйгамбәребездән соң үзләрен пәйгамбәр дип санаучылар – кяферләр.

Барлык мөселманнар да Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрләрнең соңгысы булуына һәм, аның гомере бетү белән, вәхиләрнең тәмамлануына ышаналар. Моңа каршы килүчеләр диндә шиксез беленгән нәрсәне инкяр итәләр, һәм алар мөселман түгел.

**42.** Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм – Аллаһы яраткан мәхлүкатларның иң күркәме.

**43.** Кыямәт көнендә Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм һәм башка пәйгамбәрләр, салаватуллаһи галәйһим әҗмәгыйн, гөнаһлы мөэминнәр өчен шәфәгать итәчәкләр.

**44.** Пәйгамбәрләрнең пәйгамбәрлекләрен дәлилләүче һәм исбатлаучы могҗизалары була.

**45.** Әүлияләрнең (изге кешеләрнең) кәрамәтләре була ала, әмма алар пәйгамбәрлеккә дәгъва итмиләр.

**46.** Бернинди әүлия дә пәйгамбәр дәрәҗәсенә ирешә алмый.

Пәйгамбәрләр гөнаһсыз, һәм һәрвакыт, изгелекләренә карамастан, гөнаһлардан сакланмаган әүлияләрдән өстен.

**47.** Аллаһы пәйгамбәрләренә Үзенең тыю һәм әмерләре бәян ителгән китапларны иңдергән, әмма кешеләр аларны үзгәрткәннәр. Ә соңгы Илаһи Китап – Коръән. Аны Аллаһы Үзе сакларга вәгъдә иткән.

Пәйгамбәребезгә кадәр дә үз өммәтләренә Аллаһының Ихтыярын ирештерүчеләр булган, әмма бу китаплар үзгәртелгәннәр, ә Пәйгамбәребез барлык кешелек дөньясына җибәрелгән, һәм ул алып килгән Китап үзгәрүләрдән һәм бозулардан сакланган.

**48.** Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм уяу халәтендә Кодес шәһәренә күчерелә, ә аннан күкләргә ашырыла.

Гомеренең иң авыр чорларында – халкы аңа нык каршы килгәндә – Пәйгамбәребезгә Аллаһы Үзенең рәхмәтен ирештерә: Ул аны уяу хәлендә Кодес шәһәренә күчерә. Бу вакыйга Исра вакыйгасы дип атала, һәм бу вакыйганы кире кагу, инкяр итү көферлек санала, чөнки Исра вакыйгасы Коръәндә хәбәр ителә. Кодестан Пәйгамбәребез күкләргә ашырыла. Бу вакыйга Мигъраҗ дип атала.

**49.** Пәйгамбәребез ирештергән Кыямәт көне билгеләре – Дәҗҗал, Гайсәнең килүе, кояшның көнбатыштан чыгуы – хак билгеләр.

Аллаһы Пәйгамбәребезгә Кыямәт көне җитүенең билгеләрен ирештергән. Алар гөнаһлар арту, биек биналар төзүдә ярышу һ.б. кебек кече билгеләргә һәм кояшның көнбатыштан чыгуы һ.б. кебек зур билгеләргә бүленәләр.

Кыямәт көне билгеләре арасында – Гайсәнең күктән Димәшкъ шәһәренә төшүе, аның Пәйгамбәребез Мөхәммәд өммәтеннән булуы һәм Дәҗҗалга каршы көрәшүе.

**50.** Бу өммәттә Пәйгамбәребездән соң иң хәерле кеше – Әбү Бәкер, аңардан соң Гомәр, Госман, аннан – Гали. Бу хәлифәләрнең хакимлеге рас һәм Пәйгамбәребезнең Сөннәтенә туры килә.

Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать вәкилләре бу тугры хәлифәләрнең Пәйгамбәребез вафатыннан соң хакимлекләре тәртибенчә, сәхабәләр арасында иң өстеннәре буluларын таныйлар.

■ Мөфти **Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН**

*(Дәвамы киләсе санда)*



Фото: shutterstock.com

# Рус миссионерларының татар муллалары хакында фикерләре

Урта Идел буе халыкларының этнографиясен һәм көнкүрешен өйрәнгәндә без җирле халыкларның тормышы белән танышуда рус миссионерларының аерым роль уйнаганын күрәбез. Алар татар халкын өйрәнүгә дә үз өлешләрен керткән. Миссионерлар Ислам диненнән куркыныч яный дип уйлап ялгышсалар да, татар-мөселман халкына каршы булсалар да, аларның күбесе татар халкында Ислам диненең үзенчәлекләре, татар халкының көнкүреше, гореф-гадәтләре хакында дөреслеккә туры килгән мәгълүмат калдырган.

Мондый тикшерүчеләр арасында Коблов Яков Дмитриевичне билгеләп үтәргә кирәк. Ул Казан руханилар академиясен тәмамлый һәм алга таба магистр була. 1901 елдан 1908 елга кадәр Яков Коблов Казан епархиаль миссионеры вазифасын башкара, ләкин ул вакытта рухани дәрәҗәсендә булмый. Аның татар халкы турындагы тикшеренүләре кыйммәтле этнографик чыганак булып тора.

Әлеге мәкаләдә без Кобловның революциягә кадәр Рәсәйдәге татар муллалары хакында бәян итүе белән танышабыз. Татар-мөселман авылларында булганда Коблов, иң беренче булып, әлеге мөһим фактка игътибар итә: кайсы гына авылны алса да, зур яки кечкенә булуына карамастан, анда мәчет урнашкан була. Аның фикеренчә, әлеге истәлекле факт мөселман татарларының беренче чиратта дини мәнфәгатьләрен кайгыртуларын ассызыклый.



● *1871-1878 еллардагы мәчет. Фотоның чыганагы: Бөек Петр (Кунсткамера) исемендәге антропология һәм этнография музее*


Коблов мулла кешенең мөселман җәмәгатьчелегендә, мәхәлләдә җитәкче, имам булуын әйтә. Моннан тыш, мулла мәхәлләдәгеләрнең дин тәртипләрен үтәвен күзәтә һәм берниндидә хаталарны читтә калдырмый. Ул, чыннан да, җәмәгатьчелекнең җитәкчесе ролен башкара һәм барысы да аңа итагать итә.

Коблов мулла булган кешенең мәхәллә халкы белән бик тыгыз элемтәдә торуын әйтә. Гадәттә бу вазифаны шушы мохиттән булган кеше башкара. Мулла, башкалар кебек үк, авыл хуҗалыгы эшләре белән шөгыльләнә һәм бу мәсьәләдә башка татар крестьяннарыннан аерылмый. Башкалардан ул дөньяви һәм дини эшләрдән күбрәк хәбәрдар булуы белән генә аерылып торган. Ул мәхәллә халкының тормышын яхшы белә, чөнки үзе дә алар белән бер төрле тормыш алып бара. Шуңа да мәхәллә халкы белән җитәкчелек итү аңа авыр түгел.

Аеруча да Коблов игътибарны түбәндәге фактка юнәлтә: мулла кеше мәхәллә халкын үзенә тышкы авторитеты яки нинди дә булса өстенлекләре белән түгел, ә, барыннан да бигрәк, рухи ягы, акыллы булуы һәм җәмәгатьчелекнең асылын аңлый алган кеше булуы белән буйсындыра. Коблов татар авылындагы мулланың вазифалары күп булуын ассызыклый. Ул намаз укыту гамәлен башкаручы да, балалар мөгаллиме дә, тормыш-көнкүрештәге эшләрдә киңәшче дә һәм хәтта казый да.

Шуңа күрә мөселманнарның мәктәптә укып белгән дингә ышанулары, карашларының ныклыгы көчсезләнми, ә, киресенчә, гыйлемле җитәкче кулы астында ныгый һәм гомерлеккә сеңеп кала.


Коблов муллаларның көнкүрешенә кагылышлы кызыклы искәртүләр дә калдырган: аерым алганда, мулла иseme кешегә берниндидә өстенлекләр һәм хокуклар бирми. Шуңа да мулла – ул гадәти крестьян, бары тик читтән кергән хезмәт хакы аркасында башкалардан бераз аерылып тора. Зур керемнәре булмаса да, ул җитеш тормышта яши һәм аның артык ихтыяҗлары юк.



● *Мулла кешенең йорты. Иске Йорт авылы.* Фото ТРның Милли музееннан

Мулланың өс киеме мәхәллә халкыныкы кебек үк. Йортында да башкаларда булган әйберләр генә: шул ук урын җир, кирәк-яраклар урын алган. Аның йорты башкаларныкыннан дини әдәбиятның күп булуы белән генә аерылып тора.

Моннан тыш, Коблов, мәхәллә халкына мулланың йогынтысы зур булуын билгеләп үтә. Мулланы мәхәлләдә хөрмәт итеп кенә калмыйлар, ә күпмедер дәрәҗәдә (сүзнең уңай мәгънәсендә, билгеле) аннан куркалар да. Әгәр урамда яшьләр төркеме уеннар белән мавыгып торса, тавышланса, кычкырып җырлар җырласа, шул вакытта йортыннан чыккан мулланы күреп, алар тын калалар, хәтта иң батырлары да кая туры килсә шунда качып тору ягын карый.



● *Фотоның чыганагы: Бөек Петр (Кунсткамера) исемендәге антропология һәм этнография музее*

■ **Дамир ГАЙНЕТДИНОВ** язмасы,
**islam-today.ru** сайтыннан тәрҗемә

# Адәм баласының биш сыйфаты

***Адәм баласын Яратучысыннан яхшырак белүче юк. Әйе, безне бу дөньяга яраткан Раббыбыз безнең хакта барысын да белә. Хәтта без белмәгән якларыбыздан, сыйфатларыбыздан да Ул хәбәрдар. Гаҗәп, әмма кеше гомер буе да үзен тулысынча өйрәнеп бетермәскә мөмкин. Бары тик Раббыбыз гына безнең барлык кимчелекләребезне, зәгыйфь якларыбызны белә һәм шуңа да безнең өчен кайбер нәрсәләрне әмер итә, ә кайберләреннән тыя. Кем ул адәм баласы? Ул нинди сыйфатларга ия? Кеше үзе хакында каян белә ала? Бу сорауларга җавапны Изге Китабыбыз – Коръәни Кәримнән табарга тырышыйк.***

*1. Адәм баласы зәгыйфь итеп яратылган*

**“...кеше [шәһвәтле тойгыларга каршы] зәгыйфь буларак яратылган”.**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:28

Без зәгыйфь халәттә бу дөньяга киләбез һәм шул ук халәттә бакыйлыкка күчәбез. Әмма бу очракта зәгыйфьлек тәнгә генә кагылмый. Кеше рухи яктан да зәгыйфьлеккә дучар. Шуңа да ул Раббысына сыенырга, Ислам дине нуры астында яшәргә тиеш. Дога, зикер, гыйбадәт, һәрдаим шөкер кылу һәм гөнаһлардан, хата-кимчелекләрдән ерак булу кешене ныгыта, бу дөньяның авырлыкларына каршы торырга ярдәм итә.

*2. Адәм баласы ашыгучан итеп яратылган*

**“Кеше ашыгучан итеп яратылган. [Болай итеп ашыгу, аның табигатенең аерылмас бер төсен алган...”.**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:37

Еш кына ашыгу, сабырсызлану адәм баласына зыян сала. Ул шул рәвешле хаталар җибәрергә мөмкин. Дөнья дип, гамәл-гыйбадәтләребездә, бигрәк тә намазыбызны укыганда ашыгу да моңа керә. Вакыйгаларны ашыктырып, сабырсызлык күрсәтүебез дә Раббыбызга тәвәккәл итүебезгә комачау итә. Юкка гына өлкәннәр: “Сабыр төбе сары алтын”, – дип әйтмәгән. Сүз дә юк, ашыктырырга кирәк булган гамәлләр дә бар. Мәсәлән, намазны вакыты кергәч тә укырга тырышу. Шуңа күрә әлеге сыйфатыбызны белеп, аны дөрес итеп куллана алсак иде.

*3. Адәм баласы сабырсыз итеп яратылган*

**“Һичшиксез, кеше сабырсыз буларак яратылган”.**

«Әл-Мәгариҗ / Баскычлар», 70:19

Бу сыйфат югарыда искә алынган “ашыгучан” сыйфатыбыз белән тәңгәл. Әмма бу очракта сабырсыз булуны тагын бер ягыбыз белән чагыштырырбыз. Адәм баласы еш кына авырлык килгәндә сабырлык күрсәтми, шул рәвешле үзенә зыян сала һәм Раббысының рәхмәтеннән ерагая. Бу урында Раббыбызның әлеге аятен дә искә алып үтик:

**“Ий иман китерүчеләр! Сабырлык һәм намаз аша [Аллаһы Тәгаләдән] ярдәм сорагыз. Һичшиксез, Аллаһы сабыр итүчеләр белән”.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:153

Димәк, Аллаһы Тәгалә сабыр итүче кешеләрне Үзенең ярдәменнән, рәхмәтеннән мәхрүм итми. Бу аятьтә безгә нинди хәлдә булсак та аннан чыгу юлы барлыгы хакында әйтелгән – ул сабырлык һәм намаз белән Раббыбыздан ярдәм сорау. Моннан чыгып, сабырсыз булуның безгә берничек тә ярдәм итә алмавын аңлыйбыз.

*4. Адәм баласы шөкерсез итеп яратылган*

**“...Һичшиксез, кеше – Раббысына шөкер кылмаучы”.**

«Ән-Нәср / Ярдәм», 100:6

Кешенең чираттагы сыйфаты – ул аның шөкер кыла белмәве. Әйе, адәм баласы авыр вакытта сабырлык күрсәтә белмәгән кебек, рәхәт вакытта шөкер дә әйтә белми. Расүлебез: «Кем иртә белән иминлектә, саулыкта, бер көнлек ризыгы булган халәттә йокыдан уянса, ул җир йөзенең бөтен байлыгына ия кеше кебек булыр», – дигән (имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан). Бу хәдисне барыбыз да белсә дә, күпләр аңа тиешле игътибар бирми. Галимнәр адәм баласының рәхәткә сабыр итә алмаганын ассызыклаган. Шөкер кыла белмәүгә икенче яктан да карарга кирәк. Без шөкерне бар яктан да җитеш булганда гына түгел, ә гомумән, нинди хәлдә дә кылырга тиеш, чөнки нинди кыен вакытларда да шөкер итәр өчен сәбәпләр бар һәм Раббыбыз берәүгә дә күтәрә алмаслык йөк йөкләми. Ул: **“...шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә [нигъмәтләрне тагын да] арттырачакмын”**, – дип әйткән.

«Ибраһим», 14:7

*5. Адәм баласы онытучан итеп яратылган*

**“Кешегә [авыру һәм фәкыйрьлек кебек] бер яманлык кагылса, янтыкка яткан килеш, утырып яки аягөсте Безгә ялвара. Әмма Без аңардан ул бәлане алгач, үзенә кагылган бәла турында Безгә һич дога кылмаган кебек [тәкәббер хәлендә булуын] дәвам итә”.**

«Юныс», 10:12

Бу сыйфат та шөкерсез булу белән тәңгәл. Кеше, кызганычка, Раббысының биргән нигъмәтләре хакында бик тиз оныта, әмма килеп туган кыенлыкларга бик тиз канәгатьсезлек белдерә һәм үзенә бирелгән нигъмәтләрне онытканлыгы аркасында шөкерсезлек белдереп, гафләттә яши башлый.

Бирелә адәм балаларының Корьәндә килгән кайбер сыйфатлары гына искә алынды. Кызганычка, кешегә тәкәбберлек, көнчелек, башкалар турында начар уйлау, гайбәт сөйләү, яла ягу һәм башка бик күп начар гадәтләр дә хас була ала. Еш кына кеше алардан котыла алмаска да мөмкин. Әмма ул бу сыйфатларны белеп, үзенең хата-кимчелекләрен төзәтергә тырышып яшәсә, һичшиксез, уңышка ирешәчәк. Раббыбыз безнең көчле рухлы, сабыр, шөкер итүчән, күркәм холыклы булып яшәүләребезне насыйп итсә иде.

**Айсылу ЮЛДАШЕВА**



Фото: shutterstock.com

# Пәйгамбәребезнең күркәм сыйфатлары һәм үзенчәлекләре

*Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең искиткеч күркәм халәте башка кешеләргә, хәтта башка бер пәйгамбәргә яки фәрештәгә дә хас түгел, ул бары тик аның шәхесенә генә хас. Аллаһы Тәгаләнең соңгы пәйгамбәре һәм соңгы Расүле – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм башка пәйгамбәрләрдән үзенең камил, сәламәт тәне, пакь күңеле һәм күркәм әхлагы белән аерылып тора. Шул сәбәпле, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзенә генә хас булган күркәм сыйфатлары һәм үзенчәлекләре бар. Аларның кайберләрен карап үтик.*



Фото: shutterstock.com

### Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә исеме белән генә дәшәргә ярамый

Элеккеге кабиләләр үз пәйгамбәрләренә исемнәре белән эндәшә алганнар. Ләкин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә болай рөхсәт ителми.

**“Ий, иман китерүчеләр! [Пәйгамбәремнең янында ни дә булса әйтергә кирәк булганда] тавышларыгызны Нәбинең тавышыннан югарырак күтәрмәгез, бер-берегезгә кычкырып дәшкәнегез кебек, аңа да көр тавыш белән дәшмәгез, юкса гамәлләрегез бушка чыгар, сез исә абайламассыз да”.**

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:2

Әлеге аять иңгәнчегә кадәр сәхабәләр Аллаһының Расүленә: “Ий Мөхәммәд! Ий Әбү Әл-Касыйм!” дип эндәшкәннәр. Бу аять иңгәннән соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бу рәвешле мөрәҗәгать итү, эндәшү рөхсәт ителмәгән. Сәхабәләр Аллаһының Расүленә: “Йә Нәбиуллаһ! Йә Расүлуллаһ!” дип эндәшә башлаганнар.

### Раббыбыз Пәйгамбәребезгә җирдәге барлык урынны да чиста кылды

Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм аның өммәтенә җирдәге барлык урынны да чиста кылды. Тәһарәт алырга су булмаган очракта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә тәяммүм алырга рөхсәт ителде. Шушы җиңеллек аның өммәтенә дә таралды.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә бу хакта болай дип әйтә:

**“Әгәр сез [су кулланырга ярамаслык хәлдәге] авыру яки сәфәрдә булсагыз, яки сезнең берәрегез [хаҗәтен үтәп] хаҗәтләнү урыныннан килсә, яки хатыннар белән [якынлык кылып] бер-берегезгә кагылган булсагыз һәм [тәһарәт, йә госел алырга] су тапмасагыз, пакь туфракка юнәлегез дә, йөзләрегезне һәм кулларыгызны аның белән [мәсех кылып] сыпырыгыз. Аллаһы [сезне тәһарәт, госел һәм тәяммүм кебек вазифалар белән җаваплы тотып] сезгә кыенлык тудырырга теләми”.**

«Әл-Маидә / Табын», 5:6

Җирдәге барлык чиста урынны Аллаһы Тәгалә намаз укыр өчен яраклы итте. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кадәр булган пәйгамбәрләрнең кавемнәренә гыйбадәтләрен бары тик гыйбадәтханәләрендә генә үтәргә мөмкин иде.

### Расүлебез бер кавемгә генә җибәрелмәде

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кадәр килгән пәйгамбәрләр аерым бер халыкка, аерым кавемгә җибәрелгән булсалар, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм билгеле бер кавемгә генә түгел, ә Кыямәт көненә кадәр булачак бөтен кешелеккә һәм җеннәргә җибәрелгән.

### Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм – иң соңгы пәйгамбәр

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм – иң соңгы пәйгамбәр. Аннан соң пәйгамбәрләр булмаячак. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәригате Кыямәт көненә кадәр гамәлдә булачак.

### Галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән

Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хакында Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**“[Расүлем!] Без сине [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек”.**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә сөекле пәйгамбәребез Мөхәмәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрде. Яшәгән дәверендә һәм вафатыннан соң да Аллаһының Расүле барлык кешеләргә, җеннәргә, фәрештәләргә, хайваннарга, кошларга, гомумән, барлык тере һәм тере булмаган мәхлүкъларга рәхмәт булып тора.

### Аллаһы Тәгалә Расүлебезне иң олы дәрәҗәләргә күтәрә

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә пәйгамбәрләргә мөрәҗәгать иткәндә һәрберсенә дә үз исемнәре белән эндәшә. Ә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иң хәерле рәвештә күркәм сүзләр белән: “Ий Минем пәйгамбәрем! Ий Минем Расүлем!” – дип мөрәҗәгать итә. Бу сүзләр аша Раббыбыз Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дәрәҗәсен күтәрә.

**Мөинетдин Мөхәммәд Әмин Хиравиның “Алты Бармак”** китабыннан тәрҗемә

# Расүлебезнең тормышыннан сабак алырлык гыйбрәтле кыйссалар



## Күркәм холык нәтиҗәсе

Бу хәл пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдә ислам динен тарата башлаган чорда була. Иман китермәгән олы яшьтәге бер әби базарда шактый күп әйберләр сатып алып көчхәл белән өенә кайтып барганда, аңа күркәм кыяфәтле бер ир кеше дәшә һәм үзенең ярдәмен тәкъдим итә. Карчык бу тәкъдимне сөенеп кабул итә һәм алга таба алар юлны инде бергәләп дәвам итә. Әйтергә кирәк, бу вакытта мәккәлеләр ике капма-каршы төркемгә бүленгән була: Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөйләгәннәрен кабул итүчеләр һәм кабул итмәүчеләр. Икенче төркем тарафдары булган карчык аңа ярдәм итеп барган яшь иргә зар-интизарын белдерә башлый:

– Өемә кадәр әле шактый ерак – бераз сөйләшеп алсак та була. Шәһәрдәге хәлләрдән хәбәрдәрдер бит? Габдулла улы Мөхәммәд исемле кеше үз фикерләрен тарата башлагач, тормыш әллә нишләп китте бит әле: безнең бабаларыбыз динен кире кага, янәсе, гыйбадәткә бер Аллах кына лаек, фәкать Аңа гына буйсынасы, Аны гына зурлыйсы! Ә без гомер буе табынган илаһлар дөрес түгел, имеш! Менә сиңа мә! Тапкан нәрсә сөйләргә! Тыныч яшәдек моңарчы, ә хәзер?

Шулай сөйләнә-сөйләнә, әби Габдулла улы Мөхәммәдне тиргәпәрләп, аның хакында бик начар, мыскыллы сүзләр әйтеп, юл буе дулап кайтты. Аны озата баручы ир исә дәшмичә тыңлап кына барды. Үз йорты янына килеп җиткәч, карчык аңа ярдәм иткән иргә дәшеп, ахыргы нәсыйхәтен бирде:

– Син, улым, мин әйткәннәрне онытма: шул Мөхәммәд атлы кешене тыңлама, аңа берүк иярә күрмә! Аңладыңмы? Ярый, улым, мин кайтып җиттем, зур рәхмәт сиңа! Бу шәһәрдә безнең кебек өлкәннәргә ярдәм итәм дип атлыгып тормыйлар шул... Бөтенесе үзен генә кайгырта... Ә син – менә нинди ярдәмчел, олы күңелле кеше булып чыктың! Үзең кем буласың соң, исемең ничек?

Әбине озата барган ир аның әйберләрен капка янындагы эскәмиягә куеп, елмаеп җибәрә дә, башын аска иеп, әкрен генә тавыш белән әйтә:

– Габдулла улы Мөхәммәд мин...

Шушы исемне ишетүгә, әби сискәнеп куя, аннары каушаудан калтырап, дерелдәгән тавыш белән сорый:

– Ничек?... Исемең ничек дисең??...

– Габулла улы Мөхәммәд! – дип инде ышанычлы тавыш белән кабатлый яшь ир.

Әллә оялудан, әллә бик нык дулкынланудан карчык үзе дә сизмәстән тезләнә һәм ике кулын да күккә таба күтәреп, кычкырып куя:

– Шәһәдәт бирәм ки, юк илаһ Аллаһтан башка һәм шәһәдәт бирәм ки, Мөхәммәд Габдулла улы Аның колы һәм илчесе!!!

Шулай итеп, мөселманнарга, аларның пәйгамбәренә тискәре, хәтта агрессив мөнәсәбәттә булган кеше ислам динен кабул итә. Моның сәбәбе, әлбәттә, пәйгамбәребезнең күркәм холкы. Шулай ук бу кыйссадан тагын шундый сабаклар да алырга мөмкин:

– Әби Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм турында гайбәткә, имеш-мимешләргә нигезләнеп фикер йөрткән, шуңа күрә аның турында начар фикердә булган. Безгә моннан сабак алып, беркайчан да фактларны тикшермичә, кеше сүзенә генә ышанып кемдер яки нәрсәдер турында нәтиҗә ясарга ярамый.

– Әгәр кемдер безгә йөзебезгә бәреп начар, авыр сүз әйтсә, сабыр булып калырга кирәк. Шушы тасвирланган хәлдә Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әбинең ләрләү, мыскыллау сүзләренә түзмичә, аңа тупас итеп җавап биргән булса, ул, әлбәттә, ислам динен кабул итмәс иде.

## Өметкә хакы бар

Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сахәбәләре белән урамнан барганда юл кырыенда яткан бер исереккә юлыга. Сахәбәләр бу шыксыз бәндәне күрүгә, җирәнүдән башларын читкә борып, тизрәк үтеп китмәкче булалар, әмма Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм кинәт туктап кала. Җирдә йоклап яткан ирнең чуалып беткән чәчләре, килбәтсез тырпаеп торган сакалы, пычранып беткән ертык киеме һәм бик ямьсез, хәтта куркыныч ачылып калган авызы чыннан да ифрат кызганыч, рухи мәгънәдә бик авыр халәтне чагылдыра иде.

Бераз вакыт тынлыкта узды. Сахәбәләр шул кеше өчен оялудан нишләргә, нәрсә әйтергә дә белмичә: "Нәрсә дияр инде рәсүлебез? Әй әләгәчәк инде хәзер бу адәм актыгына..." – дип уйлап куярга өлгерми, Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм юлдашларын шаккатырып болай ди:

– Карагыз әле, бу кешенең тешләре нинди матур!

Шуннан соң пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм башын аска иеп бераз уйланып тора да, борылып юлын дәвам итә. Хәйран калган сахәбәләр исә "Мәә шәә Аллаһ! Сүбеханәллаһ!" – дия-дия аның артыннан юнәләләр.

Шулай итеп Аллаһның илчесе сахәбәләргә үзенчәлекле дәрес бирә: бик күп начар сыйфатларга ия булган кешедә дә ниндидер яхшы сыйфаты була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең начарлык арасында шул яхшы якны күреп ала белүе бик түбән дәрәҗәгә төшкән бәндәнең дә ӨМЕТКӘ, МӘРХӘМӘТЛЕЛЕККӘ, ИГЕЛЕКЛЕ МӨГАМӘЛӘГӘ, БӘХЕТКӘ ХАКЫ БАР булуын күрсәтте. Өметсез шайтан гына. Ә кешедә – ул нинди хәлдә булуга карамастан – гел өмет бар. Бу Адәм балаларына булган Аллаһның олуг РӘХМӘТЕ.

## Синеке дә дөрес

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккәдән Мәдинәгә күченеп килүе Мәдинә шәһәре халкы өчен зур бәйрәмгә әверелде: барысы ихлас шатланды, Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылды, рәсүл әкрамның Мәдинәгә күченүен ансарлар аларга ирешкән Аллаһның олуг рәхмәте булуын яхшы аңлый иде. Әмма Адәм балаларының холыктабигатьләре төрле булу сәбәпле, шушы гомум сөенечле көннәрдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә "мәрхәбә" тойгыларын гына түгел, салкынчарак мөнәсәбәт белдерүчеләр дә була.

Көннәрдән бер көнне Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм сахәбәләре белән бергә утырганда, аның янына килгән бер ансар, киң елмаеп әйтә:

– Безгә күченеп килүегез бик әйбәт булган, чөнки безнең шәһәрдә олы күңелле, инсафлы, бик яхшы кешеләр яши. Әлхәмдүлилләһ!

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә ихлас елмаеп, аңа болай җавап бирә:

– Сүзең хак. Дөрестән дә, бу шәһәрдә бик яхшы кешеләр яши!

Күпмедер вакыт узгач, шул ук урынга икенче кеше килеп керә. Йөзен кара болыт каплагандай, сүрән чырайлы бу бәндә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә канәгатьсез, төксе итеп карап болай ди:

– Безгә күченеп килүегез бер дә әйбәт булмаган. Беләсегез килсә, бу шәһәрдә бик начар кешеләр яши.

Сахәбәләр Аллаһ рәсүле бу кешенең сүзенә ничек җавап бирер икән дип эчтән генә уйлап, тын калдылар. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә ирен читләре белән елмаеп, кыска гына бер җөмлә әйтте:

– Синеке дә дөрес.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шушы ике кеше белән сөйләшүеннән хәйран калган сахәбәләр аптырап болай диләр:

– Йә рәсүлуллаһ! Ни өчен шәһәребездә яхшы кешеләр яши дигән кардәшебезгә җавап биргән кебек, шәһәрдә начар кешеләр яши диючегә дә "сүзең дөрес" дип җавап бирдең?

– Моның хикмәте бик гади, – диде Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм. – Кеше күңелендә нәрсә йөртә – шуны табачак. Әгәр кешеләр турында яхшы уйлыйсың икән, алар сиңа яхшы булып күренәчәк, ә инде башкалар турында начар фикердә булсаң, алар да синең өчен начар булачак...

Мөбарәк хәдисләрнең берсендә шундый бер хәл риваять ителә. Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сахәбәләр белән мәчеттә утырганда аларга әйтә: "Хәзер монда керәчәк кеше – Җәннәт әһеле". Шуннан соң мәчеткә бер кеше килеп керә дә алар барысы бергә намаз укый. Намаздан соң кайтканда, сахәбәләр бу кешедән: "Җәннәткә кертерлек нинди гамәлең бар?" – дип сорыйлар. Теге кеше башта аптырап кала, соңыннан исә әйтә: "Әллә ни артык гамәлем юк. Шуны гына әйтә алам: мин кешеләр турында начар сөйләгәнем генә түгел, хәтта начар уйлаганым да юк".

Менә шулай, җәмәгать! Башкалар турында начар уйламыйча яхшы фикердә булсаң, күңелең гел тыныч, йөзең нурлы, әйләнә-тирә якты, дөнья матур, ә тормыш бәхетле булып тоелыр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә моны үзенең күркәм үрнәгендә бик яхшы аңлатты.

■ **Ришат хәзрәт КУРАМШИН,**
Кукмара мәдрәсәсе мөдире,**"Яшәеш сабаклары"** китабыннан

+12

**Хөрмәтле радиотыңлаучылар!**

«Азан» радиосын azan.fm сайтында яки «Азан» радиосы рәсми кушымталары аша тыңлагыз. Моның өчен түбәндәге QR-код аша үтегез яки App Store (iPhone өчен) һәм Google Play Market (Android өчен) платформаларыннан «Азан радиосы» кушымтасын йөкләп алыгыз.

**QR – кодлар:**

Android өчен:

iPhone өчен:

**Сайт:** azan.fm
**Инстаграм:** azan.fm
**Вконтакте:** azanfm
**Телеграм-канал:** azanfm

**Почта:** radio@azan.fm
**Тел.:** 8 (843) 598-09-43

**ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ**

0:00 Коръәни Кәрим – 0+
6:05 Коръән тәфсире – 12+
6:25 Көндәлек догалар – 6+
6:30 Тынычлык тәгълимате –12+
7:05 Таян Аллаһка – 6+
7:20 Хәзрәткә сорау –12+
7:30 Иман тәме –12+
7:50 Миллият сүзлеге – 6+
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар – 6+
8:05 Бәхет тулы йорт –12+
8:30 Күңелдән күңелгә –12+
8:50 Шәхесләргә шәрехләр – 6+
9:00 Рухи хәзинә – 6+
9:15 Гыйбадәте Исламия – 6+
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) –12+
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.) –12+
10:40 Миллият сүзлеге – 6+
10:45 Көндәлек догалар – 6+
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака – 6+
11:00 40 хәдис – 6+
11:20 Аллаһның 99 исеме – 6+
11:30 Мәчетләребез тарихы – 6+
11:40 101 вәгазь –12+
12:00 Өйләгә азан – 0+
12:10 Гыйбадәте Исламия – 6+
12:25 Миллият сүзлеге – 6+
12:30 Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә –12+
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт –12+
14:10 Әхлак баскычлары – 6+
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы –12+
14:45 Сөннәт юлы –12+
15:05 Коръән тәфсире –12+
15:25 Көндәлек догалар – 6+
15:45 Бәхет тулы йорт –12+
16:05 Миллият сүзлеге – 6+
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар – 6+
16:20 101 вәгазь –12+
16:40 Күңелдән күңелгә –12+
17:00 Шәхесләргә шәрехләр – 6+
17:10 Гыйбадәте Исламия – 6+
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака – 6+
17:40 40 хәдис – 6+
19:30 Әдәбият күрке әдәп – 6+
19:45 Миллият сүзлеге – 6+
20:00 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)–12+
20:20 Һәр яхшы сүз – сәдака – 6+
20:30 Нәниләргә нәсыйхәт – 6+
20:35 Пәйгамбәрләр тарихы –12+
20:50 Көндәлек догалар – 6+
21:10 Мәчетләребез тарихы – 6+
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.) –12+
21:50 Хәзрәткә сорау –12+
22:00 Гыйбадәттә сәгадәт –12+
22:10 Әхлак баскычлары – 6+
22:37 Миллият сүзлеге – 6+
22:45 Аллаһның 99 исеме – 6+
23:00 Коръәни Кәрим – 0+

**ҖОМГА**

0:00 Коръәни Кәрим – 0+
6:00 Җомга тәбриге –12+
6:05 Коръән тәфсире –12+
6:25 Көндәлек догалар – 6+
6:30 Тынычлык тәгълимате –12+
7:05 Таян Аллаһка – 6+
7:20 Хәзрәткә сорау –12+
7:30 Иман тәме –12+
7:50 Миллият сүзлеге – 6+
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар – 6+
8:05 Бәхет тулы йорт –12+
8:25 Җомга тәбриге –12+
8:30 Күңелдән күңелгә –12+
8:50 Шәхесләргә шәрехләр – 6+
9:00 Рухи хәзинә – 6+
9:15 Гыйбадәте Исламия – 6+
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) – 12+
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.) – 12+
10:00 Җомга тәбриге – 12+
10:40 Миллият сүзлеге – 6+
10:45 Көндәлек догалар – 6+
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака – 6+
11:00 40 хәдис – 6+
11:20 Аллаһның 99 исеме – 6+
11:30 Мәчетләребез тарихы – 6+
11:40 101 вәгазь – 12+
12:00 Өйләгә азан – 0+
12:10 Гыйбадәте Исламия – 6+
12:25 Миллият сүзлеге – 6+
12:30 Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә – 12+
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт – 12+
14:10 Әхлак баскычлары – 6+
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы – 12+
14:45 Сөннәт юлы – 12+
15:00 Җомга тәбриге – 12+
15:05 Коръән тәфсире – 12+
15:25 Көндәлек догалар – 6+
15:45 Бәхет тулы йорт – 12+
16:05 Миллият сүзлеге – 6+
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар – 6+
16:20 101 вәгазь – 12+
16:40 Күңелдән күңелгә – 12+
17:00 Шәхесләргә шәрехләр – 6+
17:10 Гыйбадәте Исламия – 6+
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака – 6+
17:40 40 хәдис – 6+
19:30 Әдәбият күрке әдәп – 12+
19:45 Миллият сүзлеге – 6+
20:00 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) – 12+
20:20 Һәр яхшы сүз – сәдака – 6+
20:30 Нәниләргә нәсыйхәт – 6+
20:35 Пәйгамбәрләр тарихы – 12+
20:50 Көндәлек догалар – 6+
21:10 Мәчетләребез тарихы – 6+
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.) – 12+
21:50 Хәзрәткә сорау – 12+
22:00 Гыйбадәттә сәгадәт – 12+
22:10 Әхлак баскычлары – 6+
22:37 Миллият сүзлеге – 6+
22:45 Аллаһның 99 исеме – 6+
23:00 Коръәни Кәрим – 0+

**ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ**

0:00 Коръәни Кәрим – 0+
6:05 Коръән тәфсире – 12+
6:25 Көндәлек догалар – 6+
6:30 Тынычлык тәгълимате – 12+
7:05 Таян Аллаһка – 6+
7:20 Хәзрәткә сорау – 12+
7:30 Иман тәме –12+
7:50 Миллият сүзлеге –6+
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар –6+
8:05 Бәхет тулы йорт –12+
8:30 Күңелдән күңелгә –12+
8:50 Шәхесләргә шәрехләр –6+
9:00 Рухи хәзинә –6+
9:15 Гыйбадәте Исламия –6+
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) –12+
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.) –12+
10:40 Миллият сүзлеге –6+
10:45 Көндәлек догалар –6+
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака –6+
11:00 40 хәдис –6+
11:20 Аллаһның 99 исеме –6+
11:30 Мәчетләребез тарихы –6+
11:40 101 вәгазь –12+
12:00 Өйләгә азан –0+
12:10 Гыйбадәте Исламия –6+
12:25 Миллият сүзлеге –6+
12:30 Кәлам Шәриф. Тәрҗемә –12+
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт – 6+
14:10 Әхлак баскычлары – 6+
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы –12+
14:45 Сөннәт юлы –12+
15:05 Коръән тәфсире –12+
15:25 Көндәлек догалар –6+
15:45 Бәхет тулы йорт –12+
16:05 Миллият сүзлеге –6+
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар –6+
16:20 101 вәгазь –12+
16:40 Күңелдән күңелгә –12+
17:00 Шәхесләргә шәрехләр – 6+
17:10 Гыйбадәте Исламия –6+
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака –6+
17:40 40 хәдис –6+
19:30 Әдәбият күрке әдәп –12+
19:45 Миллият сүзлеге –6+
20:00 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) –12+
20:20 Һәр яхшы сүз – сәдака –6+
20:30 Нәниләргә нәсыйхәт –6+
20:35 Пәйгамбәрләр тарихы –12+
20:50 Көндәлек догалар –6+
21:10 Мәчетләребез тарихы –6+
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.) –12+
21:50 Хәзрәткә сорау –12+
22:00 Гыйбадәттә сәгадәт –12+
22.10 Әхлак баскычлары –6+
22:37 Миллият сүзлеге –6+
22:45 Аллаһның 99 исеме –6+
23:00 Коръәни Кәрим –0+

# Казан өчен ноябрь аена намаз вакытлары

| Көн | Көн исеме | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Зәүвәл | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01.11.2021 | Дүш | 04:43 | 05:19 | 06:49 | 11:27 | 12:00 | 14:10 | 16:03 | 17:48 |
| 02.11.2021 | Сиш | 04:45 | 05:21 | 06:51 | 11:27 | 12:00 | 14:08 | 16:01 | 17:46 |
| 03.11.2021 | Чәрш | 04:47 | 05:23 | 06:53 | 11:27 | 12:00 | 14:06 | 15:59 | 17:44 |
| 04.11.2021 | Пәнҗ | 04:49 | 05:25 | 06:55 | 11:27 | 12:00 | 14:04 | 15:57 | 17:42 |
| 05.11.2021 | Җом | 04:50 | 05:28 | 06:58 | 11:27 | 12:00 | 14:03 | 15:55 | 17:40 |
| 06.11.2021 | Шим | 04:52 | 05:30 | 07:00 | 11:27 | 12:00 | 14:01 | 15:53 | 17:39 |
| 07.11.2021 | Якш | 04:54 | 05:32 | 07:02 | 11:27 | 12:00 | 13:59 | 15:51 | 17:37 |
| 08.11.2021 | Дүш | 04:56 | 05:34 | 07:04 | 11:27 | 12:00 | 13:57 | 15:49 | 17:36 |
| 09.11.2021 | Сиш | 04:57 | 05:36 | 07:06 | 11:27 | 12:00 | 13:55 | 15:47 | 17:34 |
| 10.11.2021 | Чәрш | 04:59 | 05:38 | 07:08 | 11:27 | 12:00 | 13:54 | 15:45 | 17:32 |
| 11.11.2021 | Пәнҗ | 05:01 | 05:40 | 07:10 | 11:27 | 12:00 | 13:52 | 15:43 | 17:31 |
| 12.11.2021 | Җом | 05:03 | 05:42 | 07:12 | 11:27 | 12:00 | 13:50 | 15:41 | 17:29 |
| 13.11.2021 | Шим | 05:04 | 05:44 | 07:14 | 11:27 | 12:00 | 13:49 | 15:40 | 17:28 |
| 14.11.2021 | Якш | 05:06 | 05:46 | 07:16 | 11:27 | 12:00 | 13:47 | 15:38 | 17:27 |
| 15.11.2021 | Дүш | 05:08 | 05:48 | 07:18 | 11:28 | 12:00 | 13:46 | 15:36 | 17:25 |
| 16.11.2021 | Сиш | 05:09 | 05:50 | 07:20 | 11:28 | 12:00 | 13:44 | 15:35 | 17:24 |
| 17.11.2021 | Чәрш | 05:11 | 05:52 | 07:22 | 11:28 | 12:00 | 13:43 | 15:33 | 17:23 |
| 18.11.2021 | Пәнҗ | 05:12 | 05:54 | 07:24 | 11:28 | 12:00 | 13:41 | 15:31 | 17:22 |
| 19.11.2021 | Җом | 05:14 | 05:56 | 07:26 | 11:28 | 12:00 | 13:40 | 15:30 | 17:20 |
| 20.11.2021 | Шим | 05:15 | 05:58 | 07:28 | 11:29 | 12:00 | 13:38 | 15:28 | 17:19 |
| 21.11.2021 | Якш | 05:17 | 06:00 | 07:30 | 11:29 | 12:00 | 13:37 | 15:27 | 17:18 |
| 22.11.2021 | Дүш | 05:19 | 06:02 | 07:32 | 11:29 | 12:00 | 13:36 | 15:26 | 17:17 |
| 23.11.2021 | Сиш | 05:20 | 06:04 | 07:34 | 11:29 | 12:00 | 13:35 | 15:24 | 17:16 |
| 24.11.2021 | Чәрш | 05:22 | 06:06 | 07:36 | 11:30 | 12:00 | 13:34 | 15:23 | 17:15 |
| 25.11.2021 | Пәнҗ | 05:23 | 06:08 | 07:38 | 11:30 | 12:00 | 13:33 | 15:22 | 17:15 |
| 26.11.2021 | Җом | 05:24 | 06:10 | 07:40 | 11:30 | 12:00 | 13:31 | 15:20 | 17:14 |
| 27.11.2021 | Шим | 05:26 | 06:11 | 07:41 | 11:31 | 12:00 | 13:30 | 15:19 | 17:13 |
| 28.11.2021 | Якш | 05:27 | 06:13 | 07:43 | 11:31 | 12:00 | 13:30 | 15:18 | 17:12 |
| 29.11.2021 | Дүш | 05:29 | 06:15 | 07:45 | 11:31 | 12:00 | 13:29 | 15:17 | 17:12 |
| 30.11.2021 | Сиш | 05:30 | 06:17 | 07:47 | 11:32 | 12:00 | 13:28 | 15:16 | 17:11 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Октябрь саны, №10 (315)*

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррир: **Хәләфетдинова Л.Г.**, **Юлдашева А.И.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сабирова Ф.И.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДһӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2540
Газетага ярты елга язылу бәясе – 170,04 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 26 нчы октябрьдә таратыла.
График буенча бу санга 25 нче октябрь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.